

## Диагноз

Сәламәтлек саклау министры Адел Вафин «ШК»га яман шеш авыруы белән көрәш юллары турында сөйләде

4-5 БИТЛӘР



## Бәхет сере

60 ел бергә яшәгән Вәлиуллиннар: «Тигезлектә озак яшәүнең сере ак күлмәкләр белән зурлап туй уздыру, кыйммәтле балдакларда да түгел, бездә аның берсе дә булмады. Барысы да Ходайдан бирелгән гомер, һәм аны шөкер итеп яши белергә кирәк. Башкаларга да безнең кебек яшәргә язсын», – диләр.

10 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

# Шәһри Казан

татмедиа

**Пәнҗешәмбе** | 12.05.2016 | № 49 (5667) www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

# ЧӘЧӘКЛӘРГӘ КАРА...

**Алмагачлар, шомыртлар шау чәчәктә утыра инде. Ә без... көне буе шул бакчада бөтерелеп йөреп... шул чәчәкләрне күрмәгәнбез. Үләннәр шытканын күрми калабыз... Яфрак ярган чакны... Чәчәк аткан мәлне... Ләкин шунысы бәхәссез: чәчәкләрне күрер өчен, чәчәкләр булу гына җитми...**

6 БИТ



Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы



Азнакайда калифорния суалчаннары үрчетәләр

6-7 БИТЛӘР



«ШК» журналисты республикадагы бердәнбер остадан гармун ясау серләрен өйрәнеп кайтты

5 БИТ

## РЕСПУБЛИКАДА

### КАЙБЫЧ

Идел буе федераль округында уздырылган «Җиңү» иҗтимагый проекты кысаларында оештырылган «Иң яхшы музей» республикакүләм конкурсында Кайбыч районы беренче урынга лаек булган.

### АРЧА

Узган елны – Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан, арчалылар Суслонгер лагеренда һәлак булган якташларына һәйкәл урнаштырган иде. 9 Май бәйрәме алдыннан район хәрби комиссары Алмаз Борһанов җитәкчелегендә бер төркем арчалылар әлеге һәйкәлне тәртипкә китереп, чәчәкләр куеп кайткан.

### БАЛТАЧ

Балтач мәктәбе укучысы – волонтер Зилә Хәсәнова, Анапа шәһәрендә узган «Карта добра» форумында катнашып, икенче урынга лаек булган. Кызны ГТОның алтын значогы белән бүләкләгәннәр.

### АЛЕКСЕЕВСК

Иртәгә Алексеевскида сәламәтлек саклау хезмәткәрләре спартакиадасы узачак. Аларны биредә җиңел атлетика, бадминтон, волейбол, теннис, шахмат, канат тартышу ярышлары көтә.

### ӘТНӘ

Җиңү көне уңаеннан, Дусым авылында обелиск ачылган. Кечкенә генә Дусым авылыннан гына да Бөек Ватан сугышында 128 кеше һәлак булган, сугыштан исән кайткан 37се дә озак яшәмәгән.

### ТҮБӘН КАМА

Шәһәрнең 35енче микрорайонында Күршеләр аллеясе дигән акция узган. Аның кысаларында, микрорайон территориясендә 60 төп агач утыртылган, чирәм җәелгән, чүп-чар җыештырылган.

### КАМА ТАМАГЫ

Районда гадәти булмаган шоу узган. «TRESPASSERS MCB» Казан мотоклубы байкерлары катнашында мотоцикллар чыгышыннан торган шоуны тамаша кылырга бик күп тамашачы җыелган.

**Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды**

# Үрдәккә дә субсидия бирәләр

**Эшлим дигән колына – чыгарып куяр юлына дигән кебек, авыл җирлекләрендә кош-корт асраргa теләүчеләргә дә быел хөкүмәт беренче тапкыр субсидияләр бирә башлаган. Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының реструктуризацияләү һәм агробизнесны үстерү бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе Ольга Петровадан без субсидия алу нечкәлекләре турында сораштык.**



Зөлфия Хәлиуллина фотосы

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА**

– Быел беренче тапкыр шәхси хуҗалыкларда үстерелүче кош-корт өчен дәүләт субсидия бирә. Бройлер чебиенең һәр башына – 30 сум, үрдәккә – 80 сум, каз белән күркәгә – 100 сум. Субсидия алуның билгеле бер шартлары бар: кош-кортларны 1 июньгә кадәр республика территориясендә урнашкан кош-корт хуҗалыклары, инкубаторларыннан гына алу зарур һәм аларның яше 1 айдан артмасын. Тагын бер шарт – кош-кортларның саны 50дән алып 100гә кадәр булырга тиеш. Субсидияләр күләме сатып алынган яшь кош-корт хакының 50 процентыннан артмаска тиеш, транспорт чыгымнары субсидиягә керми. Сатып-алу килешүе төзелгәннән соң, чеби, үрдәкне кимендә ике ай, каз белән күркәне дүрт ай асрау мәҗбүри, – дип сөйләде ул безгә.

Субсидия алу өчен 1 июньгә кадәр район башкарма комитетына гариза язасыз. Анда түләү реквизитлары, сатып алынган кош-кортның һәр төре буенча баш саны, почта адресы һәм сатып алынган яшь кош-кортның сакланышын тәэмин итү бурычы күрсәтелергә тиеш; сатып алынган кошлар өчен түләүне һәм кошларның кошчылык хуҗалыкларыннан сатып алынуын раслый торган документларның (сатып-алу килешүе, кабул итү-тапшыру актлары, түләү кәгазьләре (квитанция яисә касса чегы), накладнойлар һәм ветеринария белешмәләре) күчермәләре, шәхси ярдәмче хуҗалыкларның хуҗалык исәбе кенәгәсеннән яшь кошларны министрлык тарафыннан расланган рәвеш буенча исәпкә кую фактын раслый торган өземтә тапшырыла.

Кош-кортлар, куелган таләпләрдәге вакыттан алда авырудан үлгән очракта, башкарма комитетка ветеринария белешмәсен һәм бракка чыгару турындагы актны тапшырасы була.

Ольга Петрова сүзләренә караганда, субсидия алырга теләүчеләр шактый.

– Күрше күршесеннән күреп тә, дусты танышыннан ишетеп тә килә-ләр. Субсидия бирүнең дә максаты – кош итен җитештерү һәм сату күләмен арттыру. Күп булган саен яхшы, – ди ул.

Моннан тыш, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә ярдәм итү максатыннан да субсидияләр биреләчәк (районнар билгеләгән лимитлар кысаларында). Шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнарга сөт юнәлешендә мини-фермалар төзүгә, таналар сатып алуга, токымлы ана кәҗәләр сатып алуга, сыерларны ясалма орлыкландыру хезмәтләрен күрсәтү чыгымнарын каплауга, өч яшьтән зуррак булган үгезләрне тоту өчен азык сатып алуга, сыерларга профилактик ветеринария хезмәтләре күрсәтү чыгымнарын каплауга субсидияләр алырга мөмкин.

## СӨБХАНАЛЛА!

# Татарстанның иң өлкән кешесенә – 110 яшь

Бүгенге көндә Татарстанда 100 яшеннән узган 187 кеше бар. Хатын-кызлардан иң өлкән әби – Кадерниса Шәфигуллина Әлмәттә яши. Аңа быел 110 яшь тулачак. Ә иң өлкән бабай Яшел Үзән районында гомер кичерә. Аңа быел 107 яшь тула.

# Шәһәр кәефе



**ИЛДАР ВӘЛИЕВ,**
инженер:

– Казанда тудым, шушында белем алдым. Миңа башка шәһәр кирәкми, үзебезнең Казан яшәсен. Велосипедта йөрергә яратам, эшкә дә велосипедта йөрим. Урамда юл кагыйдәләрен белергә кирәк, әлбәттә. Транспорт чаралары белән идарә итүчеләрнең күбесе велосипедчыларга игътибарлылык күрсәтә. Шәһәр читендә автоһәвәскәрләр өчен «Автомәйдан» булдырылсын иде. Яшьләр кичләрен шунда җыелышыр иде.



**АНЯ ЗАХАРОВА,**
укучы:

– Мәктәптән сыйныфыбыз белән Казан читендәге Иннополис фән шәһәрчегенә экскурсиягә бардык. Иннополис бөтенләй башка дөнья, анда белем алучылар башка югары цивилизация вәкилләре кебек. Мин үзем дә фән белән кызыксынам. Иннополиста булганнан соң, фән юнәлешендә белем алырга һәм фән өлкәсендә эшләргә дигән карарга килдем. Киләчәк тормышымны фәкать Казанда гына күрәм.



**ФЛЮРА ГАЛИУЛЛИНА,**
пенсионер:

– Әтием Бикчәнтәй сугыштан инвалид булып кайтты. Бик тырыш кеше иде, бахыр. Гаиләдә биш бала үстек, тамак туймый калган чаклар да була иде. Җиңү хәбәре килгәч, Казан халкы урамнарга тулды. Казан 1945 елларда зур авыл кебек кенә иде әле ул. Казанлылар бер гаилә сыман аралашып, ярдәмләшеп яшәде. Бүген шәһәр галәмәт зурайды, кеше кешене белми. Җиңү бәйрәмендә халык бергә туплана, үзен көчле итеп тоя.



**ГӨЛНӘФИС ВӘЛИЕВА,**
хезмәткәр:

– Бала чагым Себердәге Томск шәһәрендә узды. Кияүгә чыгып, Казанга кайтканыбызга да утыз ел узды инде. Хезмәт юлым мәдәният өлкәсе белән бәйле. Җәйне үлеп яратам. Бакчабызга барып, тәүге уңыш җыеп кайттык инде. Редискалар өлгерде, күпеллык суган үзе бер тәмле сөенеч. Кибеттән яки базардан сатып алынган яшелчә, җиләк-җимеш ул күңелне кузгатмый. Бакчада үз кулларың белән җыю җан рәхәтлеге бирә.



**РАМИЛ ГАЛИЕВ,**
студент:

– Башкортстанның Стәрлебаш районыннан килдем Казанга. Монда инженер белгечлегеүзләштерәм. Быел дүртенче курсны тәмамлыйм, диплом эше язам. Алла боерса, аннан соң ике ел магистратура. Баштарак туган җир сагындыра иде, ияләштем инде. Казан нык ошый, шәһәр елдан-ел матурлана, үсә. Казанда барлык милләтләргә дә мөнәсәбәт әйбәт, уку һәм хезмәт мөмкинлекләре бик зур.

# ОСАГО алу өчен, торакны иминиятләштерергә кирәк?!

**1 июльдән ОСАГО полисларының яңалары барлыкка килүе турындагы закон 11 февральдә үк кабул ителсә дә, иминиятләштерү компанияләрендә бу хакта әле дә төгәл белүче юк. Яңа ОСАГОның өстенлекләре дә сер булып кала бирә. Аның каравы, яңа бланкның эскиз проекты «Российская газета»да басылып чыкты.**


ptzgovorit.ru

Эльвира МОЗАФФАР

Баксаң, бүген Россиядә 4 миллионга якын ялган ОСАГО полисы кулланыла икән. Алдалауларга нокта кую өчен, ышанычлы бланклар булдырырга кирәк дип тапканнар. Яңа бланкта барысы да яңача: шрифт, билгеләрнең үлчәме дә үзгәргән. Яктыда караганда, бланкта «полис» сүзен, машина сурәтен дә күрергә мөмкин. Бланкта урнаштырылган махсус QR код ярдәмендә полис, автомобиль, аның хуҗасы турында тулы мәгълүмат та алып булачак. Кыскасы, мондый саргылт-алсу төстәге яңа бланкларны 1 июньгә үк өлгертергә җыеналар. Автомобиль иминиятләштерүчеләрнең Россия берләшмәсе хәбәр итүенчә, июньнән иминият компанияләренә барлыгы 15 миллион яңа бланк таратылачак.

Татарстан иминият компанияләре агентлары исә бу мәсьәләдә артык борчылмаска киңәш итә. Куллану вакыты чыкканчы, ОСАГО полисының искесе белән дә йөрергә мөмкин булачак. Иң мөһиме – ул закон нигезендә эшләнгән булсын. Ә 1 июльдән үк полисны яңасына алыштырырга теләгәннәргә бу хезмәтне иминиятләштерү компанияләре бушлай башкарачак, диделәр.

Яңа полис алу бер хәл, хәзер искесен алу баш бәласенә әйләнгән, ди. Күп иминиятләштерү компанияләре, ОСАГО полисын биргәндә, өстәмә хезмәтләрдән файдаланырга мәҗбүр итә. Әйтик, «Росгосстрах» үзенең гомеренә иминиятләштерүгә куша, «Итиль Армеец»та фатирыңны иминиятләштерүне таләп итәләр.

– ОСАГО полисларын бирү компания өчен отышлы түгел. Хәзер, яңа кагыйдәләр буенча, бер юл һәлакәте булса, иминиятләштерү компаниясе 400 мең сумга кадәр түли. Шәһәрдә машина йөртүчеләрнең күбесе авылда теркәлгән. Авыл теркәлүе белән иминиятләштерү күпкә арзанрак. Без үзебезгә зыянга эшли алмыйбыз бит инде. Шуңа да өстәмә хезмәтләр тәкъдим итәбез. Казанда бөтен иминиятләштерү компанияләре шулай эшли. Бу хакта әйтеп тормый икән, димәк, ул өстәмә хезмәтне ОСАГО бәясенә кертkән була, – ди брокер компаниясендә хезмәткәр.

– Әгәр кешенең торагы булмаса, нәрсә иминиятләштерәсең?

– Балаларны куркынычсызлык очрагыннан, үзеңнең сәламәтлегеңне дә иминиятләштерергә була. Иң арзаны – торакны иминиятләштерү, бу хезмәт якынча 1500 сумга төшә.

– Әйтик, үзебездә җитештерелгән 100 ат көченнән артмаган машинаны иминиятләштерү ничә сумга төшәчәк?

– Әгәр юл һәлакәте теркәлмәгән икән, машина йөртүченең стажы җитәрлек булса, ОСАГО полисы 11 мең сум тирәсе торачак.

– Әгәр өстәмә хезмәтләрдән баш тартсам?

– ОСАГО бирмибез генә. Ә полиссыз йөргән өчен, штраф салына.

Болай да ОСАГО полисы бер ел эчендә 108 процентка арткан иде югыйсә. Аның каравы КАСКО тарифлары күпкә арзанайган икән. «Уралсиб» иминиятләштерү төркеме белгечләре әйтүенчә, Мәскәүдә КАСКО ясату уртача 17 процентка кимегән. Казанда да агентлар КАСКО өчен өстәмә ташламалар вәгъдә итә.

## Быелгы ифтарда ун мең кеше катнашачак

**Рамазан ае башланырга бер айдан азрак вакыт калып бара. Татарстан Мөселманнары диния нәзарәте дүртенче республикакүләм ифтарга әзерлек эшләрен башлап җибәрде, дип хәбәр итте безгә Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин.**

– Быелгы ифтар ашын да «Казан-Арена» стадионында уздырырга ниятлибез. Көне әлегә билгесез. Ифтарда катнашучыларның саны елдан-ел артып бара. Быелгысында ун мең кеше катнашуы көтелә. Чыгымнарны Россия мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе күтәрәчәк.

Ифтар ашын уздырырга бер мең волонтер да кирәк булачак. Аларны нәзарәтнең яшьләр бүлеге җәлеп итәчәк. Һәр елны ифтар ашына зур кунаклар, чит илдән нашид җырлаучылар чакырылды.

– Быел да булачак алар, әмма әлегә кемнәр киләсен әйтүе кыен, иң элек ифтарны уздыру көнен тәгаенләргә кирәк, – ди мөфти урынбасары.

Сүз уңаеннан, беренче ифтар 2011 елда Казанның Меңьеллык мәйданында 1500гә якын кеше катнашында узды, 2014 елда оештырылган икенче ифтарга «Казан-Арена» стадионына 2 меңнән артык кеше җыелды, үткән елгы өченче ифтар шул ук стадионда 5 мең кешегә әзерләнгән иде.

**Дилбәр ХИСМӘТУЛЛИНА.**

*Хаҗ кылырга теләүчеләр өчен күңелле яңалык: хаҗилар изге сәфәргә, «Супер эконом» дигән яңа программа нигезендә, 120 мең сумга гына бара ала. Мөселманнарыбыз барлык уңайлыклары булган хаҗилар йортында яшәячәк. Алар башта Дубайга оча, аннары Мәккәгә хәтле автобусларда бара. Суммага ашау һәм корбан чалу бәясе кермәгән.*

*Татарстаннан мосафирлар Мәккәгә 26-27 августта кузгалачак.*

## ТОП – 5

**ГАДЕЛ КУТУЙНЫҢ** «Тапшырылмаган хатлар» әсәре буенча кино төшерергә уйлыйлар. Бу «2014-2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

**ҖИҢҮНЕҢ** 71 еллыгы уңаеннан уздырылган чараларда 24 миллион россияле катнашкан. Ул көнне илнең 8 мең торак пунктында 15 мең чара уздырылган. Иң күп халык Мәскәүдә үткән хәрби парадта (7,4 млн кеше) катнашкан. Петербург белән Ленинград өлкәсендә – 1,2 млн, Свердловск өлкәсендә – 1,01 млн, Краснодар краенда 850 мең кеше. Казандагы бәйрәм чараларын 210 меңнән артык кеше тамаша кылган.

**ИЛ** буйлап Сабан туйлары бәйрәм ителә башлады. Быел Россиянең 57 төбәгендә барлыгы 248, 28 якын һәм ерак чит илләрдә 74 Сабан туе уздыру ниятләнелә. VII Бөтенроссия авыл Сабан туе 4 июньдә – Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка эшчеләр бистәсендә, ә XVI федераль Сабантуй 16 июльдә Түбән Новгородта узачак.

**ЗӘЙ,** Апас районнары иртә чәчүне төгәлләү алдында тора – алар инде кырларның 90 проценты өлешенә культураларны чәчкән.

**КАМАЛ** исемендәге Татар дәүләт академия театры «Үлеп яратты» спектаклен бүген соңгы тапкыр күрсәтә. Ркаил Зәйдулла иҗат итеп, Илгиз Зәйниев тарафыннан сәхнәләштерелгән әлеге спектакль биш сезон дәвамында зур уңыш белән барды. Беренче татар хатын-кыз казые Мөхлисә Бубыйның авыр язмышы хакындагы әлеге драманың премьерасы 2011 елның 9 декабрендә булган иде.

АТНА ФОТОСЫ


Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

## «Көпчәкле китапханә»

Казанда гадәти булмаган гаҗәеп китапханә барлыкка килгән. Китаплар белән тулы машина торак массивларда яшәүчеләргә китапханә ролен үти. «Көпчәкле китапханә» Самосырово, Дәрвишләр бистәсендә булачак, шулай ук Имәнлек урамындагы Ветераннар йортына да барачак. Машинадан китапларны 15 көнгә алып торырга була. Проект авторлары аңлатуынча, машина, китаплар дөрес саклансын өчен, махсус эшләнгән. Һава торышы үзгәргәндә дә китапларга зыян килми. Машинада барлыгы 1,5 мең китап саклана. Аларның 60 проценты зурлар өчен әсәрләр булса, 40 проценты – кечкенәләр укый торган китаплар.

Биредә хәтта электрон китап уку билеты белән дә китап алырга була икән.

## ӘКӘМӘТ

## 31 бармаклы бала туган

Кытайда кулында – 15, ә аягында 16 бармак булган сабый туган. Баланың артык бармакларын кисеп алу өчен 30 мең доллар акча кирәк булачак. Табибларны зур сынау көтә, чөнки баланың зур бармаклары бөтенләй юк икән.



**«Бүген Татарстанда 90 меңләп кеше онкология авыруы белән исәптә тора. Бу күп! Һәр 42нче кешедә рак дигән сүз. Хатын-кызларда беренче урында – күкрәктәге яман шеш, ирләрдә – простат бизе рагы».**

# ДИАГНОЗ

## Адел Вафин яман шеш авыруы һәм аның белән көрәш турында

**Узган ел республикада Йөрәк-кан тамырлары авырулары елы булса, 2016 ел – Татарстанда Онкология авыруларына каршы көрәш елы дип игълан ителде. Апрель аенда Татарстан Президенты шул хактагы Указга кул куйды. Әлеге документ үз эченә нәрсәне ала? Яман шеш белән ничек көрәшәчәкләр? Сәламәтлек саклау министры Адел Вафин «ШК» хәбәрчесенә шул хакта сөйләде.**

– Башта ук ни өчен 2016 елны онкологиягә багышларга булганыбызны аңлатып китим әле. Узган Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш елында эшләнгән эшләр, чыннан да, үз нәтиҗәсен бирде. Беренчедән, без, гомумән, үлем очракларын киметә алдык, ә кан әйләнеше авыруларыннан килеп чыккан үлем очраклары 3,4 процентка кимеде. Өстәмә 701 кешенең гомерен саклап калдык дигән сүз бу! Моңа нәрсә тәэсир иттеме? Һәрдаим сөйләп, аңлатып тору нәтиҗәсендә кемдер кан басымын даими үлчи башласа, кемдер вакытында дару эчәргә өйрәнде. Халык безне тыңлый, ишетә башлады. Тик Татарстанда онкологиядән үлү очраклары арта бара. Шуңа күрә без быелгы елны Онкология авыруларына каршы көрәш елы дип игълан итеп, «Рак ул үлем карары түгел – диагноз, ә иң төп инструмент ул – профилактик осмотрлар, диспансерлаштыру», – дип чаң кагарга булдык.

Кагыйдә буларак, хезмәт яшендәге кешеләр күп эшли һәм сырхауханәләргә йөрергә күнекмәгән. Алар үз сәламәтлекләренә игътибар бирми диярлек. Без яман авыруның үсешен күрми, белми калабыз – төп проблема да шунда. Ә бит ракны I-II стадияләрдә ачыклаганда, ул дәвалана, кешенең гомерен саклап калып була, Татарстанда бүген моның өчен мөмкинлекләр бар. III стадиядә шансլар азрак, ә инде IV стадия икән, сүз бары тик паллиатив ярдәм турында гына бара... Монда инде авыруның хәлен бераз җиңеләйтү, сызлануларны киметергә генә мөмкин. Ә рак чыннан да шулхәтле яман авыру: ул кешене кыска гына вакыт эчендә дөньядан алып кына китү түгел (халык телендә, кеше янып бетте, диләр), үләр алдыннан гариплэтә, килбәтсез-шыксызландыра, танымаслык итә. Бу – авыруның үзе генә түгел, бөтен якыннары өчен җитди эмоциональ яра. Шуның өчен без әйдәп баручы Европа илләре, АКШтагы кебек үк, халыкның үзенә игътибарын арттыруны, авыруны башлангыч стадияләрдә ачыклауны һәм дәвалануdan курыкмауны аңлатуны төп кагыйдә итеп алдык.

Әле диспансерлаштыру программасы кергән генә елларда халык моңа өстәмә мәшәкать итеп карый иде, хәзер, шөкер, әһәмиятен аңлыйлар инде. 2014 елда диспансерлаштыру вакытында 1267 яңа онкологик авыру очрагы ачыкланса, шуларның 74 проценты беренче-икенче стадиядә иде. Узган ел авырулар саны азрак булды, әмма аларның да 68 процентын башлангыч стадиядә эләктереп алдык. Әгәр кеше үзе авырудан шикләнеп сырхауханәгә килсә, башлангыч стадияләрдә ачыклау 50 проценттан да күп булмый, ягъни соңга калып килә.

Узган ел төрле ведомстволар белән бергә нәтиҗәле эшләр башкарылды, зур мәгълүмати кампания алып барылды. Әлеге эшләр быел да дәвам итәчәк. Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш чаралары кысаларында, без, авыруны кисәтүгә өчен, төп биш кагыйдә чыгарган идек. Быел да Медицина хезмәткәрләре ассоциациясе, Идел буе федераль округының баш онкологы, министрлыкның әйдәп баручы белгечләре белән берлектә, үзенә күрә бер кулланма әзерләдек. Ул «Онкология авыруы бүген нәрсә ул?» дигән сорауга җавап бирә. Авыру нәрсәдән килеп чыга? Моңа нәрсә этәргеч булып тора? Иң мөһиме – ракны профилактикалау буенча ун кагыйдә формалаштырылды. Без аны гади, аңлаешлы тел белән эшләдек. Мин бу кулланманы Президент катнашында узган киңәшмәдә район башлыклары, министрларга, зур эш бирүчеләргә дә җиткердем. Безгә аларның ярдәме кирәк. Әйтик, Әлмәттә, шәһәр хакимияте белән берлектә, зур чара уздырдык. Анда 200ләп компания җитәкчесе килгән иде, алар каршында чыгыш ясадым. Эш бирүче беренче чиратта нәрсәгә игътибар итәргә тиеш һәм хезмәткәрләр, вакытында тиешле медицина тикшерүе узсын өчен, нәрсә эшләргә кирәк – җитәкче моны белергә тиеш. Иң кыйммәтлесе – кеше капиталы, хезмәт ресурсы бит. Хәзер менә Түбән Кама мэры шундый ук очрашу уздыру инициативасы белән чыкты. Казан, Чаллы, Яшел Үзән, Чистай кебек башка сәнәгать шәһәрләре дә кушылыр дип уйлыйм.

## ОНКОЛОГИЯНЕ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ БУЕНЧА МИНИСТРДАН УН КАГЫЙДӘ

**1. ТӘМӘКЕ ТАРТУНЫ ТАШЛАГЫЗ!**

Ракның 16 төре тәмәке тарту белән бәйле.

**2. АЛКОГОЛЬ ЭЧЕМЛЕКЛӘР КУЛЛАНМАГЫЗ!**

Бу хакта бәхәсләр шактыйдан бара. Кешеләр озак еллар алкогольнең файдасын эзли, танылган табиблар сүзләрен китерә, ятар алдыннан 50 грамм эчеп куюның файдасы турында лаф ора. Алкоголь файдасын дәлилләү максатыннан башланган бөтен фәнни эшләр уңышсызлыкка дучар: файда юк! Кызганыч, Россия халкы күп эчә, бигрәк тә каты спиртлы эчемлекләрне. Каты спиртлы эчемлекләр, көчәйтелгән шәрабләр авыз куышлыгы, бугаз һәм ашказаны-эчәк тракты рагына китерергә мөмкин.

**3. КОЯШТА ОЗАК ТОРМАГЫЗ!**

**4. ЭШ УРЫНЫНДА КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК КАГЫЙДӘЛӘРЕН ҮТӘГЕЗ!**

Сүз, әйтик, тын алу юлларын, тирене сакларга кирәк булган зарарлы эш урыннары турында бара. Куркынычсызлык кагыйдәләренә күз йомарга ярамый. Тормыштан бер мисал китерим әле. Бер автослесарь, югалмасын дип, вак детальләрне авызына каба торган була. Нәтиҗәдә аңарда ирен рагы ачыкланды...

**5. ДӨРЕС ТУКЛАНЫГЫЗ!**

Әйе, тагын туклану турында. Йөрәк-кан тамырлары авырулары елында бу хакта шактый сөйләдек, быел да дәвам итәчәкбез. Безнең туклану рационы баланслаштырылган икән, анда майлар, аксымнар, су, микроэлементлар, витаминнар тиешле күләмдә икән, бу – авыруны кисәтүнең иң төп факторларының берсе. Дөрес тукланмау – авыруга китерүче төп сәбәп.

Ничек тукланырга? Составында җитәрлек күләмдә азык сүсләре (пищевые волокна) булган продуктларны сайларга кирәк. Кызганычка, Татарстан халкының рационында ризык сүсе – клетчатка (үсемлек күзәнәкләренең тышчасы составындагы матдә) булган продуктлар аз. 2009 елда онкология авырулары арасында беренче урынга юан эчәк рагы чыкты – бу күп нәрсә турында сөйли. Кеше көненә 500 грамм җиләк-җимеш, яшелчә һәм яшел үләннәр ашарга тиеш. Ни өчендер бу хакта сүз чыккач, еш кына ниндидер экзотик җиләк-җимешләрне күз алдына китерәләр. Тик мин бу очракта үзебездә үсә торганнары турында әйтәм: кәбестә, кишер, чөгендер (бердәнбер искәрмә – чөгендер шикәр авыруы булган очракта зыянлы), слива, алма. Соңгысында азык сүсләре аеруча күп. Күптән түгел генә эшкәртелгән итнең юан эчәкләргә тәэсирен ачыклау буенча зур тикшеренүләр тәмамланды. Эшкәртелгән ит – колбасаны күп куллану юан эчәк рагы авырулары килеп чыгу очракларын 17 процентка арттыра. Һәм, әлбәттә инде, ысланган, әче, тозлы ризыкларны чикләү мөһим. Кемдер, иң тәмлесен чикләргә кирәк, дияр. Сезнең тормышыгызда бу булырга мөмкин! Ул була да. Сез кунакка йөрисез, рестораннарга барасыз, тик бу бит көн дә түгел, моның зарары юк. Ә менә көндәлек ризык файдалы булырга тиеш.

**6. АВЫРЛЫГЫГЫЗНЫ КОНТРОЛЬДӘ ТОТЫГЫЗ!**

Югары калорияле продуктлар кулланмагыз. Көн саен, ким дигәндә, 40 минут җәяү йөрегез. Мин кешегә киңәш итә торган бөтен нәрсәне үзем эшлим. Җәяү йөрү турында сөйлим икән, кич саен җәяү йөрергә тырышам. Иртән эшкә килсәң, кич кайтсаң, көндез чыгып йөрсәң – 40 минут шулай җыела инде.

**7. ТӘНЕГЕЗДӘ МОҢАРЧЫ БУЛМАГАН ТӨЕРЛӘР, МИҢНӘР БАРЛЫККА КИЛСӘ, ТӘН ТИРЕСЕ ТӨСЕ ҮЗГӘРСӘ, КАН БҮЛЕНСӘ, ТАБИБКА КҮРЕНЕРГӘ КИРӘК!**

Еш кына ниндидер симптомнар була торып та, табибларга бармаучылар очрый. Авырту да узар, үтәр әле дигән әйбер айлар буе дәвам итәргә мөмкин, ә чир бу арада арта һәм соңгы чиккә җиткерергә мөмкин.

**8. ХАТЫН-КЫЗЛАР, КҮКРӘК БИЗЛӘРЕН ТИКШЕРЕРГӘ ӨЙРӘНЕГЕЗ!**

35тән 45 яшькә кадәр хатын-кызлар елына бер тапкыр күкрәк бизләрен УЗИда күрсәтергә, аннан соң ел саен маммография узарга тиеш. Хатын-кыз үз күкрәген капшаганда ниндидер төер сизсә, табибка күренү мөһим.

**9. ИРЛӘР, СӘЛАМӘТЛЕГЕГЕЗГӘ ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!**

45 яшьтән соң ирләр ел саен табибка күренергә тиеш. Монысы катлаулырак. Хатын-кызлар барыбер сырхауханәләргә ешрак йөри. Шул ук йөклелек чорында күпме анализлар тапшыралар, даими консультацияләргә йөриләр. Гомумән, бала табу хатын-кызны табибка йөрү дисциплинасына тарта. Алар озаграк яши дә. Быел без ир-ат сәламәтлегенә зур игътибар бирәчәкбез. Июнь аенда шуңа багышланган зур форум узачак.

**10. ХАТЫН-КЫЗЛАР, СӘЛАМӘТЛЕГЕГЕЗГӘ ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!**

20 яшьтән соң елына бер тапкыр гинекологка күренү тиеш. Бу аналык муентыгы рагын кисәтү өчен кирәк.

Дәвалау мөмкинлекләренә килгәндә, Казанда Республика клиник онкология диспансерында нинди зур модернизация эшләре узганлыгы билгеле инде. Республиканың көньяк-көнчыгышында яшәүче халкы өчен дә шундый мөмкинлекләр булдырырга тырышабыз, медицина ярдәме беренче чиратта тиз барып җитә алырлык булсын, бу – безнең төп критерий. Автобуста 1,5 сәгать бару белән 5 сәгать баруны чагыштырып булмый бит инде! Узган елны Әлмәттә онкология сырхауханәсен зурайттык, химия терапиясе кәнәфиләрен арттырдык, заманча операция бүлмәсе ачтык, фототерапия бүлеге булдырдык, чыгып йөрүче паллиатив ярдәм хезмәте оештырдык – бүген алар 700 кешегә өйләренә барып ярдәм күрсәтә. Республиканың көньяк-көнчыгышыннан 94 процент авыру Казанга инде куелган диагноз белән хастаханәгә ятарга килә. Элеккеге кебек диагноз кую өчен чиратлар торып утыру юк. Хәзер Әлмәттә Төбәк нурланышлы терапия үзәген проектлау эшләре бара. Ягъни моңа кадәр Казанда гына мөмкин булган методлар якын киләчәктә Әлмәттә дә булачак.

**– Адел Юнысович, әйе, мөмкинлекләр дә бар кебек, тик ни өчен статистика канәгатьләнерлек түгел? Ни өчен үлем очраклары арта?**

– Беренчедән, бу – авыруны ачыклау очраклары арту белән бәйле.

Башка сәбәпләр дә бар. Әйтик, ни өчен Чаллыда яман шеш авыруы очрагы күбрәк? Чөнки шәһәр картая. Моннан 40 ел элек, аннан да элегрәк Чаллыга яшьләр килеп, кала төзеде, хәзер алар олыгайды инде. Һәм барысы да бергә олыгайды. Шуңа авыру очраклары да күбрәк.

Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, уртача гомер озынлыгы арту да онкология белән авыручылар саны артуга китерә. Без кешене инсульттан, инфарктан саклыйбыз, алып калабыз. Ә онкологиягә кешенең иммун системасы какшау тәэсир итә. Еллар узган, кеше олыгайган саен, иммунитеты кими. Картлар, балалар кебек, еш авырый. Бу бөтен дөньяда шулай. 80 яшькә таба ул авыру барыбер килеп чыгачак, уртача гомер озынлыгы арта барган саен, авыру ихтималы да арта, безнең бурыч – аңа әзер булу. Бездә үлемгә китергән авырулар арасында беренче урында йөрәк-кан тамырлары авырулары булса, чит илләрдә – онкология, чөнки анда халык озаграк яши.

Үлем очракларын киметүгә авыруны беренче-икенче стадияләрдә ачыклау йогынты ясый дип юкка гына әйтмим. Кешенең үз сәламәтлегенә игътибарлы булуы, аны кадерләве, бәяләве һәм беренчел билгеләр барлыкка килүгә, сырхауханәгә мөрәҗәгать итүе мөһим.

# ГАРМУНЧЫ

«ШК» журналисты республикадагы бердәнбер остадан тальян ясау серләрен өйрәнеп кайтты

**Татарстанда гына түгел, якын тирәдәге чит төбәкләрдә дә бердәнбер оста гармун ясаучы ул Айрат Харисов. Татарстанның халык артисты мәрхүм Рөстәм Вәлиев тә аның гармуннарында яратып уйный иде. Айрат абый турында ишетеп кенә белә идем, быел Бөтенроссия татар эшмәкәрләре җыенында үзе белән танышырга насыйп булды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та аның тальянда сызыдыруына сокланып, премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтовка Айрат абыйга ярдәм күрсәтергә йөкләмә биргән иде.**



Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

**Айрат Харисовның үзе ясаган гармунда уйнавын shahrikazan.com сайтында тыңлый аласыз.**

Эльвира МОЗАФФАР

## «БЕРЕНЧЕ ТАЛЬЯН 1 МИЛЛИОНГА САТЫЛДЫ»

Айрат абый тумышы белән Башкортстанның Борай районы, Кәшкәләү авылыннан. Гаиләдә алар алты бала үсәләр. Әтисе – оста гармунчы Зөфәр абый, улына кечкенә чагында ук «Казан» сүзе язылган гармун бүләк итә. «Шул чакта ук язмышымны Казан белән бәйлисем билгеле булган, күрәсең», – дип елмая әңгәмәдәшем. Балачак истәлекләрен йотлыгып тыңлыйм. Матур сөйләү осталыгы әнисе – татар теле һәм әдәбияты укытучысы Бәһиҗәт ападан күчкән.

Мәктәпне тәмамлагач та, Айрат, абыйсы юлыннан китеп, рәссам һөнәрен үзләштерә. Олы абыйлары Ринат Харис кебек Россиянең атказанган рәссамы булып китмәсә дә, рәсем ясау осталыгы бар. Шулай да гармунга булган мәхәббәт үзенекен итә.

– Башкортстан дәүләт педагогия институтының соңгы курсында укыганда, диплом эше өчен гармунда уйнаучы бабай сурәтен ясарга тиеш идем. Тик күңел гармунның үзен ясап карарга талпына. Ике дә уйламый, авылга кайттым да, әтинең чормадагы иске гармунын табып, шуны яңартырга керештем. Уфада танылган гармун ясау остасы Җидеяр Мөхәяровның остаханәсе бар иде. Аңа ярдәм сорап бардым, минем төп остазым, үрнәк алырдай кешем ул булды, бүген дә аңа рәхмәтлемен. Виртуоз гармунчы да иде Җидеяр абый. Балачагыннан уйный. Алар нәселләре белән гармун ясау осталары булганнар. Җидеяр абый югары белемле профессиональ музыкант иде. Кызганыч, арабыздан иртә китеп барды, – ди Айрат абый.

Җидеяр аганың фотосы бүген дә әңгәмәдәшемнең бүлмәсендә эленеп тора.

Башкортстанның Дүртөйле районы Исмаил авылында сәнгать мәктәбен җитәкләгәндә дә гармунын кулыннан төшерми Айрат абый. Балаларга үзе ясаган тальяннарын өләшеп, ансамбль оештыра, уйнарга өйрәтә. Мәскәү сәхнәсендә дә чыгыш ясыйлар. Күп кенә бәйгеләрдә җиңү яулыйлар.

**– Беренче гармуныгызны сатканыгызны хәтерлисезме? Авыр булгандыр?**

– Беренче гармуным диплом эше өчен ясалган иде. Аны Җидеяр абый 1 миллион сумга сатып бирде. Ул вакытта «нульләр» бетмәгән иде әле. Авыр кичердем. Һәр гармунны да сатканда кызганыч.

**– Иң яраткан гармуныгыз бармы соң?**

– Читекченең читеге юк дигәндәй, ышанмассыз, әмма үземнең өйдә бер гармун да юк. Үзем өчен дип ясыйм да сорап алып китәләр. Күргәзмәләргә куяр өчен берничә матур гармун ясыйсы килә дә, вакыт җитеп бетми. Балалар өчен кечкенә гармуннар ясау теләге дә бар.

**– Айрат абый, гармун сатып баеп буламы?**

– Юк инде, хәзер уйнаучысы да аз бит аның. Музыка мәктәпләрендә дә иң сирәк очрый торган уен коралы – гармун. Ихтыяҗ булмагач, фабрикалар да ябылып бетте диярлек. Гармун ясаганда күз нык бетә, станокта эшләгәндә тузан, тавыш.

**– Бер гармун ничә сум тора?**

– Төрлечә, 40 меңнән башлана.

## ГАРМУНЫҢНЫҢ ТӨЙМӘЛӘРЕН НИЧЕК БЕЛЕП БАСАСЫҢ...

**– Үзегезнең осталыкны башкаларга өйрәтеп калдыру теләге юкмы? Әйтик, гармун ясаучылар мәктәбе булдыру нияте.**

– Җидеяр абый Чаллыга күченеп киткәч, мин дә, мәктәпне ташлап (ул чакта укытучы булып эшли идем), артыннан иярдем. Ике ел Чаллы-Исмаил арасын таптадым. Ике ел остазымның өендә яшәп, гармун ясау осталыгына, тальянда уйнарга өйрәндем. Чын-чынлап бу эшнең серләренә төшенергә теләгән кеше үзе эзләп таба ул останы. Минем янга да хәрби пенсионер Хәмит абый килеп йөри, яшь баянчы Фидан Хәлиуллин дәресләр ала. Киңәш сорап шалтыратучылар да күп. Өметле яшьләр булуы сөендерә.

Айрат Харисовның гармуннарын әллә кайдан танырга була. Аларда үзенә генә хас татар рухы саклана. «Татар» дип язып кую гына ул миллилекне аңлатмый, агачтан төрле бизәкләр уеп, гармунга татарлык төсмере өстим», – ди Айрат абый. Аның тальяннарында гына танылган гармун ясау остасы Җидеяр агадан калган үзенчәлекле орнамент сакланып килә. Гармунның һәр детален кулдан ясарга тырыша ул. Һәр тальянына күңел җылысы биреп эшли. Грифларын агачтан ясый, күреген каты кәгазьдән бөгә, тукымасын да үзе ябыштыра, буйый, лаклый, каешларын үзе тегә, кыңгыравын куя, көйли. Бер гармунны ясарга уртача бер ай вакыт китә, ди.

– Гармун матурлыкны ярата. Шуңа да күрекләрен ялтыравыклы итәргә, ташлар белән бизәргә, уен коралына матур «күлмәкләр» кидерергә тырышам, – ди оста.

**– Гармун ясауда иң авыры нәрсә?**

– Кулдан эшләнгән җиз телле гармунның яңгырашы әллә кайдан аерылып тора. Уен коралы фабрикаларында эшләнгән әзер телләр белән эшләүчеләр очрый. Тик телләрне кулдан ясый белүче юк диярлек була. Бу – гармун ясауда иң төп мөһим нәрсә. Минем махсус музыкаль белемем дә юк, нота да танымыйм, беренче тальянымны ясаганда хәтта бер генә музыка уен коралында да уйный белми идем. Телләрне ясаганда, көйне тою, сизгер булу кирәк. Аларны, гадәттә, җиз чыбыктан тапап ясыйм. Бу бик четерекле, сабырлык сорый торган эш. Гармун теле артык юан да, нечкә дә булмасын, һәрберсен чиертеп карыйсың, кирәк икән, игәүлисең, кыздырасың, суытасың. Каккан да да сак булу сорала. Ахырдан гармунны көйләп бетергәч, беренче тапкыр уйнауга, нәтиҗәсен күрәсең. Бу – иң дулкынландыргыч мизгел, бала туганда елап җибәргәндәй, гармун да дөньяга уйнап аваз сала.

**– Эшмәкәрләр җыенында Президент сезгә ярдәм күрсәтәчәк дигән иде.**

– Казанга килгәнемә биш ел була. Гаиләм, хатыным Райлә, ике кызым Башкортстанда. Шуңа үзем дә бер аягым белән туган ягымда дисәң була. Остаханәм, станокларым да шунда. Былтыр гармун ясау өчен кирәкле материаллар алу өчен грант откан идем, ләкин эшләр өчен махсус бина булмау эшне тоткарлап килде. Эшмәкәрләр җыенында Президентның миңа игътибар итүе эзсез узмады. Марат Әхмәтов белән очрашып сөйләштек. Шөкер, миңа остаханә өчен бина бирелде. Тиздән шунда күченергә һәм 25 еллык тәҗрибәмне тагын да камилләштереп дәвам итәргә уйлыйм, гармун ясау минем яшәү рәвешемә әйләнде.

Мине озатыр алдыннан әңгәмәдәшем әле яңа гына ясап бетергән тальянын сынады. Гармунның телләренә кагылуга, моңлы көй агылды, Айрат абыйның йөзендә елмаю. Димәк, «яңа туган сабые» өметле. Тик бу гармуны да өендә озак тоткарланмаячак, тиздән аны Туймазыга алып китәчәкләр. «Уйныйм да, җырлыйм да» дип исемләнгән гармунда уйнап җырлаучылар бәйгесендә төп җиңүчегә шәп бүләк булачак бу тальян.

# Чәчәкләргә кара...

ГАП-ГАДИ ФӘЛСӘФӘ

**Авылда эш бетми инде ул. Яз җитсә, бигрәк тә. Мал-туарың булмаган хәлдә дә, кыш буе чүплəнгән ишегалдын тазартырга, бакчаны тәртипкә китерергә, киртә-кураның купкан җирләрен ныгытырга, тагын әллә нәрсәләр эшләргә кирәк. Менә шулай бөтерелеп йөрисең-йөрисең дә караңгы төшкәч кенә өеңә кереп, иркен тын аласың, эсвижий гәзит-журналларга күз саласың һәм «Шәһри Казан»ны кулыңа алып, андагы чәчәкләр сурәтен күргәч, бот чабып куясың: «Яп-яланаяк!.. Алмагач чәчәк аткан бит!»**

Ихатага чыгып, бакчага күз саласың – чынлап та шулай. Шау чәчәктә утыралар. Ә син... көне буе шул бакчада бөтерелеп йөреп... шул чәчәкләрне күрмәгәнсең. Моның төрле вариантлары булырга мөмкин. Үләннәр шытканын күрми каласың... Яфрак ярган чакны... Чәчәк аткан мәлне... Ләкин шунысы бәхәссез: чәчәкләрне күрер өчен, чәчәкләр булу гына җитми.

Үз башымнан үткәнгә әйтүем. Инәй авылда яшәгәч, җәйге ялларны гел авылда уздыра торган идем. Печәнен әзерләп китәргә кирәк, утынын хәстәрләргә, абзар-курасын ныгытырга. Иртәтаңнан кара төнгә кадәр чабасың – эш бетми... Эш бетми – отпускы бетә. Табигатьнең, авылның, җәйнең матурлыгы турында башыңа да кереп чыкмый. Авылның матурлыгын авылда яшәгән кеше күрми аны. Озын ялга кайткан кеше дә күрми, чөнки ул шушы вакыт эчендә фәлән-фәлән эшләрне эшләп бетерәм дип кайта. Ул матурлыкны күрү өчен бер генә көнгә, фәкать ял итү, кунак булу өчен генә кайтырга кирәк.

Тик без алай итә алмыйбыз. Без – эшем ияләре. «Әнә фәлән кешенең балалары кайтты да көне буе урманда яттылар да китеп бардылар. Инәләре, бөкрәеп, бакча утый», – дип сөйләячәк авыл халкы да. Без шуңа күнеккәнбез, тормышны кабул итү рәвешебез шундый.

Югыйсә берәр көн урманга чыгып ял итеп, хозурланып кайтканнан гына дөньяның бер чите дә кителеп төшми инде. Башын күтәрмичә җәй буе бакча утаган кеше дә, яшелчә-җимеш сатып, миллионер булмый. Рухи байлыгы да әллә ни артмый торгандыр. Моны хәтта Ходай да хупламыйдыр. Теге дөньяга баргач: «Әнә мин синең өчен матур чәчәкләр үстердем, табигатьнең һәр мизгелен син соклансын өчен гүзәл иттем. Син аларны күрдеңме, сокландыңмы?» – дип сораса, ни дип җавап бирерсең? «Юк шул, Алла бабай, минем алабута тамыры белән кәтмән сыртыннан башка нәрсә күргәнем булмады...» – диярсеңме. Шулай булгач, гомере буе җиргә туңкаеп яшәгән кешенең Ходай каршысында да әллә ни пачуты юктыр ул.

«Җиргә туңкаю» дигәнем әле сүз авыл турында барган өчен генә. Шәһәр кешесенең дә хәле шундый ук. Анда чапкан була, монда чапкан була. Эше уңса, тагы да дәртләнебрәк чаба, тотып тыярлык булмый. Эше уңмаса, «Болай килеп чыкмады бит әле, ныграк тырышырга кирәк бугай», – дип, тагы да тырышыбрак чаба. Берничек тә туктатырлык түгел. Туктатам дип каршы төшә күрмә – сытып, таптап, изеп китәчәкләр. Алай булмаган хәлдә дә кешенең эшенә аркылы төшәргә, аяк чалырга тырышучы дошман кебек күренәчәксең.

Ни өчен чабасың? Нәрсәгә кирәк ул?

Без, гадәттә, гаиләне аякка бастыру өчен, балалар нужа күрмәсен өчен, дип җавапларга яратабыз. Тик ни өчендер гаиләгә синең күзең тонып чабуың түгел, ә бер җылы карашың, вакытыңны алар белән үткәрү, һич югында берничә сәгать гомереңне аларга багышлау кирәк булып чыга. Балаңа да шулай. Ара-тирә башыннан сыйпап узу, аның ни әйткәнен ишетү, кирәк чакта юньле киңәш бирү. Тик безнең моңа вакытыбыз юк. Без аларны ишетмибез, күрмибез. Кирәкми дә.

Асылда, без башкалардан кимрәк күренмәү өчен, хәтта уздырып җибәрү өчен тырышабыз. Үзебезнең берданбер һәм кабатланмас икәнебезне исбатлау өчен. Гади кешеләрне узып китсәк, байлар белән ярышабыз, байларны узып китсәк, миллионерлар арасына килеп керәбез, алардан ким күренмәскә тырышабыз, аларны узып китсәң, миллиардерлар белән ярышасы, аннан тагын... Мондый узышның чиге дә, чамасы да юк. Аннан бары тик үлем, чир һәм бәхетсезлек кенә коткарырга мөмкин.

Һәм гүзәллек. Җиргә туңкайган яки озын акча койрыгына карап чапкан җиреңнән бер генә мизгелгә тукта да... чәчәкләргә күз сал... җил авазын ишет... йолдызларга кара... Кем генә булсаң да, нинди генә булсаң да, тирә-ягың тулы гүзәллек. Син беркайчан да кабатлый алмаслык гүзәллек. Аны кабатларга кирәкми дә. Күрергә һәм сокланырга кирәк. Соклана алган чакта син үзең дә шушы гүзәллекнең бер өлеше. Һәм онытма, гүзәллекне күрә белмәгән күзләрдән дә зәгыйфь нәрсә юк.

**Марат КӘБИРОВ.**



ТӘҖРИБӘ

Автор фотолары

# Азнакайда калифорния суалчаннары үрчетәләр

**Бу хикмәткә уйламаганда, моннан ике ел элек интернетта «казынып» утырганда тап була Луиза. Билгеле инде, үзенең генә күзе кызып калмый, бу хакта тизрәк озак еллар «Татнефть» тармагында супервайзер булып эшләүче ире Разин Мөхәммәтшинга да җиткерә. Шул көннән, аларның үзләрендә дә суалчан кыйссасы башлана.**

**Расиха ФӘИЗОВА**

Суалчан дигәнебез без белгән яңгыр суалчаннары түгел, ә кызыл калифорния суалчаннары. Бактың исә, тиресне шушы суалчаннардан «эшкәрттерсәң», бер дигән органик ашлама – биогумус (вермикомпост) килеп чыгасы икән. Ә бу инде, үз чиратында, химик минераль ашламалардан тулысынча баш тартып, экологик чиста продукция җитештерә башлау дигән сүз. Җитмәсә барлык культураларының уңышы 30-40 процентка артачак, үстергән яшелчә, җиләк-җимешнең тәме дә, кыяфәте дә бөрмә-бер яхшырачак икән. Билгеле инде, бөтен кеше, беравыздан, экологик чиста продукция турында сүз куерткан чакта, мондый нәрсәгә кызыкмас җиреңнән кызыгырсың. Разиннар да, икеләнеп тормый гына, тоталар да шәһәр фатирына (!) 15 тартма, ягъни 15 оя суалчан алып кайталар һәм, өч ай дәвамында, әлеге «мал»ны өйдә тоталар. Иң кызыгы шунда, тирес кортлары булсалар да, алардан бернинди ис килми. Шуның өстенә «өйрәтелгән» кебек үзләре. Тартмаларыннан шуышып чыгу турында уйлап та карамыйлар. «Кайда азык – алар шунда», – дип аңлата моны хуҗалар.

Луиза белән Разинның суалчаннары хәзер Азнакай районының Якты Юл авылында алар күптән түгел генә сатып алган ихатада төпләнгәннәр. Ишегалдына килеп кергәч, буе белән сузылып киткән салам өемнәре астында үзенә бертөрле тормыш кайнайдыр дип уйламыйсың да.

–Менә бу тирес өеме инде әзер. Менә карагыз, бернинди ис килми үзеннән. Монда хәзер суалчаннар да юк диярлек, – дип, Разин бер уч тирес алып, миңа да суза.

Чыннан да, тирес дип әйтерлеге калмаган икән шул. Парланып торган йом-йомшак җир кебек булган.

Икенче-өченче өемнәрне ачып карауга, мыжлаган суалчаннар күренде. Арада билләренә биллбау буган кебекләре дә күренә. Болары, ничек дип әйтергә инде, буаз суалчаннар булып чыкты. Кызыл Калифорния суалчаны үзе бик үрчемле дә икән. Бер ел эчендә бер суалчан 1500 үрчем бирергә сәләтле, ди. Ягъни шарты килгәндә (температура 15-30 градус, дымлылык 80 процентка кадәр һ.б.), суалчан атна саен бер кузы (кокон) сала, ә аннан, бер-ике көн дигәндә, икедән алып егермегә кадәр суалчан чыга. Ә инде 90 көн үтүгә, алар үзләре дә үрчем бирә башлый, ди. Безнең яңгыр суалчаннары 4-7 ел яшәсә, болары 14-16 ел яши икән.

– Табигать көннән-көн пычрана бара. Җирдә нинди генә калдыклар юк. Дөрес, табигатьнең үзендә дә бара утильләштерү. Әмма моңа 100 еллар кирәк. Ә нигә моны көтеп утырырга? Суалчаннар, тимер, пыяла, пластмасса һәм таштан кала, теләсә нинди калдыкны эшкәртергә сәләтле. Суалчаннар җитештергән биогумус, тирескә караганда, биш тапкыр файдалырак. Беренчедән, аңарда тирестә була торган чүп үләннәренең орлыклары юк, икенчедән, авырулар юк. Биогумусны файдаланганда, үсемлекләрдә очрый торган фитофтороз кебек авырулар да бетә, – дип, аның файдалы якларын саный Разин Мөхәммәтшин. – Көнбатышта биогумуста үстерелгән яшелчә, җиләк-җимешнең, тирес кертелгән җиргә үскәнгә караганда, кыйммәтрәк булуы мәгълүм. Чөнки анда моның файдасын күрәләр һәм алар бу эшкә күпкә иртәрәк, моннан 30 еллар элек тотынганнар.

– Кышны ничек чыктылар соң болар, салкында һаман да тирәнгәрәк китеп, качып бетмәделәрме? – дип кызыксынам хуҗалардан.

– Юк, качмыйлар. Аларны салкыннан да, суыктан да салам саклый. Тирәнлеге – ярты

метр, озынлыгы 8х3 метр итеп «оялар» эшләдек. Аларның янякларын ярты метр биеклектәге тирестән күтәртелгән бортлар белән ныгыттык. Башта аска кызыл балчык, аның өстенә әз генә кара балчык, аннан 40-50 сантиметр тирес, аннары 20-30 сантиметр салам, аның өстенә 20-30 сантиметр янмаган тирес, аның өстенә тагын шуның кадәр салам каплadык. Салам, үз чиратында, кар белән капланды. Суалчаннар акыллы. Алар беркайчан да азык булган җирдән китмиләр, кызыл балчыкка кадәр төшкән очракта да, анда азык юклыгын аңлап, кире борылалар, – дип аңлата үз суалчаннарының холкын өйрәнгән хуҗа.

Билгеле инде, Мөхәммәтшиннар үз бакчаларындагы барлык түтәлләргә дә бишкә бер исәбеннән биогумус керткән.

– Биогумусны төп саен салып-салып кына чыксаң да ярый, ә без тоташ керттек. Узган ел уңыш бермә-бер артты дип әйтә алмыйм, әмма уңышның тәме барыбер икенче булды. Без моны шунда ук сиздек. Базга салган бәрәңге, кишер, чөгендернең дә берсе бер черемәде, – дип сүзгә кушыла Луиза ханым.

Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, Мөхәммәтшиннарның суалчаннары җитештергән биогумус белән инде кызыксынучылар да шактый икән. Литр белән үлчәнә торган биогумусны капчыклап алып китүчесе дә, суалчанга дип тартма белән килүчеләр дә җитәрлек, ди. Кемгә нәрсә бит инде. Әле берәү әнә ихатасында керкә балыгы (форель) үрчетә икән дә, шуның маймычларына витамин урынына 100 процент аксымнан торган әлеге дә баягы шушы суалчаннарны алырга булган.

– Балык әле ярый, бу суалчанны киптереп, эшкәртеп, Японияда балалар өчен ризык җитештерелүе дә мәгълүм. Бер ханымның яман шештән шулар белән дәва табуын беләм. Бу суалчаннар, кай яктан карасаң да, файдага гына эшли. Дөресен генә әйткәндә, мондый эш белән теләсә кайсы бакчачы шөгыльләнә алыр иде. Чөнки кайсы гына авылга барсаң да, тиреснең чуты юк, – диләр җирне савыктыручы Мөхәммәтшиннар.

Алайга китсә, шәһәрләрдә дә чүптән күп нәрсә юк. Чүп полигоннарындагы меңтөрле калдык-постыкны, чистарту корылмаларына утырган ләмне, кибетләрдән чыгарылып ташланган яраксыз азык-төлекне, көз көне шәһәр урамнарыннан җыелган олау-олау яфракларны әлеге суалчаннарга кабат эшкәртергә кушсаң, ул чимал, гөл балчыгы булып, газоннарга кабат кайтмас идеме?

Бүген 150ләп суалчан оясы тотучы Мөхәммәтшиннарның да планнары колачлы. Алардан күреп, табигатьнең үз-үзен саклауга корылган әлеге алымны күтәреп алучылар булырмы? Анысын вакыт күрсәтер.

# Сарык – малмы?

**Озакламый көтү чыгар көннәр җитә. Элегрәк көтүнең беренче көнендә иң көяз терлек сарык булгандыр. Нинди генә буяулар сыламыйлар иде дә нинди генә чүпрәк такмыйлар иде үзләренә. Авыр туфрагы җиңел булсын, күптән мәрхүмә Сәрү әбинең сарык башына сөрткән ал буявы әле дә күз алдымда. Андый билге бер кешедә дә булмас иде...**



Автор фотосы

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Бүген инде авыл көтүләрендә сарыклар югалып бара. Берәүләр итен яратмый, икенчеләрнең көтүдән кайтмый калган бәрәннәрне эзләп йөриселәре килми. Миңа калса, иң мөһим сәбәпләрнең берсе – йон эрләп, носки, бияләй бәйләүчеләр бетеп бара, тире иләтеп, тун тектергән кешене дә күрмәссең. Сарык тотучы берничә фермер белән очрашканнан соң, хәйран калдым: йөзләгән сарыкның йонын, тиресен чүплеккә илтеп атабыз, беркем алмый, диләр. Әрәм маллар диген. Казахстан якларында эрли һәм бәйли торган машиналар кулланып, носки-бияләй җитештерәләр, бездә нигә юк икән ул? Ә, гомумән алганда, сарык асрау керемле тармак, ди фермерлар, итләтә дә, тере килеш тә сораучы күп икән.

Балтач районының Нормабаш авылыннан Булат унбиш елдан артык сарыклар асрый. Элек авылларындагы сарык фермасында эшләгән, ул беткәч, шәхси хуҗалыгында сарыклар үрчетергә тотынган.

– Узган ел бу вакытта 120 баш сарык бар иде, акча кирәк булгач, бераз киметергә туры килде, хәзергә алтмышлап баш, көтүне кабат арттырырга исәп. Сарык асрау отышлы дип исәплим, – ди ул. – Тере авырлыктан исәпләгәндә, һәр сарыктан 45-50 процент ит чыга. Тереләй баш саны белән сатарга уйласаң да, яхшы гына керем алып була, бигрәк тә Корбанга дип күп сорыйлар. Шәхси хуҗалыклар өчен яхшы токымнарның берсе – Роман токымы. Бәйлим дигән кешегә йоны яхшы, елына ике тапкыр, ким дигәндә, өч бәрән алып кайта. Барысын да сарык үзе генә имезеп үстерә алмый, иренмичә шешәдән ашатсаң, үсәләр. Алар бик хәрәкәтчән. Минем үземдә – ит бирә торган фрикос токымлы сарыклар, итләре күп чыга, йоннары кыска. Узган ел Сабантуйга биргән тәкә 105 кг лы иде.

## Сездә көтү чыктымы?

**Фидәлия Мотыйгулова, Яшел Үзән районының Акъегет авылы:**

– Авылда көтү чыкты, без – көтүчеле, бай авыл. Хәзер күп авылларда көтүче таба алмый тилмерәләр, бездә, шөкер, өчәү. Сыер башына 600 сум түлибез, төшке ашны үзләре белән алып китәләр, әзерләп бирәбез. Авылда бер көтү, барлыгы 100ләп сыер, 50гә якын сарык, кәҗә җыйнала торгандыр. Соңгы елларда көтүгә йөри торган кәҗәләр саны артты, ә сарыклар кими бара.

**Сәрия Мортазина, Арча районының Носы авылы:**

– Сишәмбе генә кан алдылар, аның нәтиҗәләре килгәч, көтү җыелышы була, шуннан соң гына көтү чыгачак. Носы белән Өчнарат авылына барлыгы 120ләп хуҗалыкка 65ләп сыер җыйнала. Сыер асраган кеше асрый инде ул, безнең үзебездә ике баш, берсе җәйгә бозаулыйсы, көтүгә әлегә чыгара алмыйбыз. Күршеләрдә дүрт баш. Көтү чираттан, тугызынчы класста укучы улым бар, ул көтә, аңа иптәшкә йә шәһәрдән кунак егетләр кайта, йә инде эш җае килсә, әтисе дә булыша. Кеше яллап көттергән юк. Яллап көттерүнең бер көне 450-500 сум йөри. Төшке ашны җәйләүгә илтәсе, кичен өйгә керәп ашап чыгалар.

**Гөлчәчәк Мөбарәкшина, Балык Бистәсе районының Иске Арыш авылы:**

– Көтү әлегә чыкмады. Өй чиратыннан көтәбез, бер сыер башына – бер көн. Кеше яллап чыгаручылар да бар. Төшке ашны биреп җибәрсәң, 500 сум йөри, үзләре өйләреннән алып чыксалар – 1000 сум. Кичке ашка кем кирә, кем юк. Авылыбызда 123 хуҗалыкка 35ләп сыер җыйнала.

## СОРАУ-ҖАВАП

**Казанда Ленин дамбасы буйлап җәяү йөрергә яратам. Ләкин тупыл мамыгы аркасында еш кына уңайсыз була иде. Аллергия булгач, авызга, борынга кергән мамыктан еш кына авырый идем. Соңгы елларда мамыксыз тупыллар да утыртып карадылар бугай. Быел да яңа төр агачлар пәйда булган. Тагын тупыл утырттылармы икән?**

**Кәримә Сафина,**
Казан.

Ленин дамбасы буйлап ел саен диярлек яңа агачлар утыртылар. Дамбаны яшелләндерү белән шөгыльләнә торган «Императорский питомник» сәүдә йорты» хезмәткәрләре аңлатуынча, тупыллар, кышкы салкыннарга, җәйге челләгә түзми, еш кына корый йә өши торган булганнар. Шуңа да агачларны еш алыштырырга туры килгән. Соңгы тапкыр тупыллар урынына 100дән артык шомырт агачы утыртканнар. «Шомырт – салкынга чыдам агач. Ул безнең климат шартларына туры килә, шулай да, теләсә кайсы үсенте кебек үк, шомыртка да җитәрлек дым кирәк. Дамбаны яшелләндерү өчен декоратив куаклыклар иң кулае булыр иде», – дип саный белгечләр.

**Эш урынында җәрәхәт алган очракта, кая мөрәҗәгать итәргә кирәк?**

**Айваз Кәримов,**
Чаллы.

Эш урынында күңелсез хәл килеп чыккан очракта, беренче чиратта хезмәтне саклау бүлегенә йә предприятие җитәкчесенә хәбәр итәргә, тиз арада «ашыгыч ярдәм» хезмәте чакыртып, зыян күргән хезмәткәрнең якыннарына бу хакта әйтергә кирәк. Башка хезмәткәрләргә курkыныч янамый икәнлеге ачыклангач, әлеге бәхетсезлек очрагы махсус журналда билгеләнгән формада теркәлә. Бу хакта әлеге эш белән шөгыльләнүче оешмаларга, әйтик, Россия хезмәт инспекциясенә, Социаль иминиятләштерү фондына, прокуратурага хәбәр ителә. Тикшерү эше башланганчы, бәхетсезлек очрагы булган урындагы әйберләрне кузгатмау яки барысын да фотога, видеога төшереп калдыру сорала. Беренче көнне үк җәрәхәт алу турында медицина белешмәсе алу да мөһим. Зыян күргән кешегә өч көн эчендә әлеге бәхетсезлек очрагы теркәлгән акт тапшырыла. Аның буенча эшкә яраксыз кешегә билгеләнгән тәртиптә иминият түләве бирелә.

**Сорау, гозер, тәкъдимнәрегезне безгә 89178516962 һәм 8(843) 562-50-03 номерлары аша шалтыратып җиткерә аласыз. «ШК» сезне тыңлый!**

# РӘХМӘТ СЕЗГӘ, ВЕТЕРАННАР!

















9 май көнне Казанда узган «Үлемсез полк» акциясендә 45 мең кеше катнашты. Колонна башында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үзе иде. Көне буе башкаланың төрле почмакларында бәйрәм чаралары гөрләде.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары



АШ БУЛСЫН!

## «Мимоза» рулеты

*Лаваш (3 данә), 250 гр майонез, 3 пешкән күкәй, 200 гр сыр, 1 банка сайра консервасы, укроп, яшел суган*

Һәр лаваш өстенә майонез сылыйбыз. Берсенә – угычта уылган күкәй, икенчесенә шулай ук угычтан чыккан сыр, өченчесенә чәнечке белән изелгән сайра балыгын җәябез. Һәрберсе өстенә ваклап туралган укроп белән суган сибәбез. Беренче лавашны рулет итеп төрәбез дә икенчесе өстенә куябыз һәм икесен бергә төрәбез. Аны өченче лаваш өстенә куеп, тагын төрәбез. Пакет эченә салып, суыткычка куябыз. Берничә сәгатьтән ашарга да була.

## Кыяр өчен витаминлы су



- Кыярдан яхшы уңыш алу өчен, аларны даими рәвештә тукландырып торырга кирәк. Моның өчен камыр башы (закваска) булыша. Аны әзерләү өчен, бер чиләк суга өч телем кара ипи салыгыз да өстен яхшылап каплап куегыз. Чиләкне бер атнага җылы урынга куегыз. Витаминлы «су»ны кыяр тамырларына сибегез. Моны, кыяр чәчәк ата башлагач, атнага бер тапкыр эшләргә була.
- Кыярның яфраклары саргайса, калий җитми дигән сүз. Бу очракта көл төнәтмәсен кулланырга кирәк. Бер литр кайнар суга ике аш кашыгы көл салып, ике тәүлек төнәтәсең. Суган төнәтмәсе дә булыша. Бер чиләк суга бер стакан суган кабыгы салып, чиләкне ут өстенә утыртырга, кайнап чыгу хәленә җиткәч, сүндерергә. Ике сәгать төнәткәч, кыяр өстенә сибәргә.

## Кишер орлыгын, чүпрәккә төреп, җиргә күмәбез

Кишер тиз тишелеп чыксын өчен, аны утыртырга ун көн кала, орлыкны чүпрәккә төрәбез дә (төенчек иркенрәк булсын) дымлы җиргә бер көрәк тирәнлегендә казып куябыз. Бу вакыт эчендә орлыкка тишелеп чыгарга комачаулый торган эфир майлары очып бетә. Ун көн үткәч, төенчекне җирдән казып алабыз. Орлыклар инде бүртеп чыккан була. Аларны савытка салып, өстенә крахмал сибәбез. Крахмал орлыкны чәчкәндә кулга ябышмасын өчен кирәк. Орлыкларны түтәлгә кирәкле интервал калдырып чәчәбез. Өстенә туфрак сибәбез. Өч-биш көннән кишер тишелеп тә чыгачак.

ХУҖАБИКӘГӘ

- Сыр тиз кипмәсен өчен, аны тозлы суга манып алынган чиста тукымага төреп куегыз.
- Сырны угычта уар алдыннан, угычка сыек май сылагыз. Алай иткәндә, сыр ябышмаячак, угычны юарга җайлы булачак.
- Кәбестә пешкән кастрүлгә бер кисәк икмәк салсагыз, аның исе бүлмәгә таралмас.
- Күкәйне каты утта пешерсәң, аның агы каты, сарысы йомшаграк булып пешә. Сүрән утта пешергәндә, сарысы каты, ә агы йомшаграк булып чыга. Шуңа да күкәйне иң яхшысы – уртача утта пешерү.

## Камыр бизәү серләре




## Ярмаңа көя төшмәгәнме?

Ашаган ризыгыбыз сәламәтлегебез өчен зыянлы булырга тиеш түгел. Аларның һәркайсының үз ярaклылык вакыты бар. Әйтик, ярмаларның да ул төрлечә.



*✓ Солы лачаулары («Геркулес») – 4-5 ай. Бу бигрәк тә төрле тәмләткечләр кушылган лачауларга карый.*

*✓ Тарының тәме 4 ай гына саклана.*

*✓ Дөге – 1,5 ел. Аның склад һәм кибетләрдә күпме ятканлыгын истә тотканда, бу вакыт арасы тагын да кыскарак. Дөгегә төрле бөҗәкләр иялэшмәсен өчен, ул саклана торган савытка берничә металл бөке яки сарымсак салып калдыралар.*

*✓ Карабодайны 20 айдан артык сакларга кирәкми.*

*✓ Манный – 14 ай. Ботка пешерер алдыннан аны, карабодай кебек үк, табада кыздырып алырга кирәк. Алай тәмлерәк була.*



## Черкиләрдән котылабыз

Черкиләрдән котылуның гаподи ысулы бар икән: лимонны икегә бүлеп, аңа канәферләр (тәмләткеч) батырып чыгабыз да йоклый торган караваты янына куябыз. Хуш ис тә килеп торачак, черкиләр дә азапламаячак.

МӘЛЕНӘ – ӘМӘЛЕ

*Шкафны ничек ясатырга белмәсәгез, түбәндәге рәсемне «өйрәнегез». Ул җыйнак та, шул ук вакытта үз эченә бик күп әйберләрне дә сыйдыра.*




## Кәбестәне валерьянка коткара

Кәбестә нык булып үссен өчен, кайбер бакчачылар даруханәдә сатыла торган валерьян даруын куллана. Өч литр суга бер шешә валерьян белән бер аш кашыгы сыегайтылган сабын салырга кирәк. Барлыкка килгән катнашманы корткычлар иялэшкән кәбестә өстенә сибәсе була. Саклауга куеласы кәбестәне алырга бер ай кала, аңа нашатырь спирты сибәләр. Моның өчен бер шешә (40 мл) нашатырь спиртын биш литр суга салып, аңа ике аш кашыгы сыегайтылган сабын салыгыз. Шул катнашма белән кәбестәне эшкәртегез.

## Эх, җаныем, чәчләрең...

Чәчләр ялтырап һәм күперен торсын өчен, шампуньга витаминнар салып юарга кирәк. Чәчне юарга җитәрлек шампуньны бер савытка салабыз, аңа даруханәләрдә сатыла торган ампулалы A, B, PP, C, B12, P6 витаминнарын кушабыз. Шул катнашма белән чәчне юабыз. Витаминнарлы шампунь савытының үзенә салырга кирәкми, ни өчен дигәндә, витаминнар, әйтик, C витамины һавада 20 минут кына «яши».

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА** әзерләде.

15 май – Халыкара гаилә көне

# «Башкаларга да безнең кебек яшәргә язсын»

## 60 ел


Автор фотосы

**Яшел Үзән районының Акъегет авылында гомер итүче Фәридә апа белән Равил абый Вәлиуллиннар инде 60 елдан артык бергә.**

– Тигезлектә озак яшәүнең сере ак күлмәкләр белән зурлап туй уздыру, кыйммәтле балдакларда да түгел, бездә аның берсе дә булмады. Барысы да Ходайдан бирелгән гомер, һәм аны шөкер итеп яши белергә кирәк, – ди Вәлиуллиннар.

Урам аша гына яшәгән, кечкенәдән бер-берсен белгән Фәридә белән Равил бер ел очрашып йөргәннән соң, язмышларын уртак итәргә уйлый. Кичтән бергә булырга сүз куешалар да икенче көнне егет кызны өенә алып кайта. Әтиәниләреннән хәер-фатиха алып, никах укыталар.

– Кечкенә генә, бер яклы йортка, ишле гаиләгә килен булып төштем, 37 ел каенана белән яшәдек. Ул чакларда кышларын сарык, бозау да шул бер өйдә бит инде. Сузгә дә киленмәгән, булганы белән яшәлгән, балачакта үги ана белән гомер итеп, авырлыкларга түзәргә өйрәнгәнмендер, күрәсең, ачлык-ялангачлыкны үз җилкәбездә татыдык, – дип искә ала Фәридә апа.

Равил абый булачак хатынын алып кайткач та, капкадан кергәнче, кисәтеп куя: «Әти-әни – үз урынында, ир үз урынында булачак, һәрберсен хөрмәтләп, гаилә учагын саклап яшәү – хатынның бурычы. Сүземнән чыкма, һәрнәрсәне киңәшләшеп эшлик», – ди. Кәләшен сайлап ялгышмый: чибәр, сөйкемле, ягымлы хатыны тугры тормыш иптәше, уңган хуҗабикә, акыллы килен, кадерле әни дә була белә. Әле хәзер дә 86 яшендә булса да, ашарга пешереп, өйләрне тәртиптә тота Фәридә апа.

Вәлиуллиннар алты бала тәрбияләп үстерәләр. Беркайчан да каеш белән куркыту булмый аларда. Үз үрнәкләрендә, сүз белән аңлатып, хезмәт белән тәрбияләр балаларын. Хәзер дә уллары Роберт, Илһам, Илшат, кызлары Гөлсинә, Фидая, Гөлинә – әти-әнисенең төп терәге, гел хәлләрен белеп торалар. 16 онык, 22 оныкчык өчен дә яраткан дәү әни белән дәү әти алар. Үзләре бүген уллары Илһам белән киленнәре Сөмбел тәрбиясендә.

Вәлиуллиннар белән бәхетле яшәү серләре турында сөйләшәбез.

– Күпме җыйсаң да, шартламыйсың. Сабыр булырга, шөкер итәргә кирәк. Һәр сүзне дә ишетмә, колак аша уткәр, каршы әйтәсе килгәндә, түзеп кал, ирең исерек булса да, тавыш чыгарма, сүз әйтмәсәң, бәхәс чыкмый ләбаса, – ди Фәридә апа. – Безне авыр чакларда ачлыктан әрекмән тамыры, алабута, кычыткан коткарып калды. Сабантуйга кияргә күлмәк алыр өчен яланаяк, тизәктән кирпеч суккanны хәтерлим. Мәктәпкә аякка чабата киеп барсак, хәзергеләр беренче класска ук телефон тотып бара. Бик иркендә яшибез. Булганның кадерен белергә кирәк. Сугышлар кабатланмасын, тынычлыкта яшәргә язсын иде.

Равил абый, гаиләдә «мин-минлек» булырга тиеш түгел, дип саный. Күп нәрсә хатын-кыздан тора, ди.

– Еллар узса да, мәхәббәт югалмый, бер-береңә якыная гына барасың, – ди алар. Авырып китсәләр, бер-берсен дога укып өшкерәләр, безнең дәва – догаларда, диләр.

## 50 ел

**Яшел Үзән районының 170 ел тарихы булган Муллаиле авылында гомер итүче Сәлимә апа белән Ризван абыйның бергә яши башлаганнарына – 50 ел.**



Сәлимә апа ишле гаиләдә үсә, җиде туганына апа була. VIII сыйныфтан соң авылда төпләнеп кала. 43 ел буена колхозда бернинди ялсыз сыер сава. Авыл кешесенең эше тавык чүпләп бетермәслек. Җәй айларында гектарлаган суган, чөгендер кишәрлеге бүлеп бирәләр, әле үз бакчаң, ихатаң... Биш баланы да тәрбиялисе бар. Гаиләдә дә хатын-кыз – җылылык, татулыкны саклаучы.

Ризван абый фронтка киткән әтисен бер тапкыр да күрми кала. Озак еллар авылларыннан ерак түгел «Албаба» тимер юл станциясендә вагон бушатучы булып эшли.

– Өйгә күбрәк акча алып кайтыйм әле, тормыш иптәшемне, кызларымны шатландырыйм, дип, кайбер көннәрне 50 килограммлы капчыкларны берьюлы икешәрне күтәреп ташыган ити. Әниебез һәрвакытта да акыллы киңәшләрен бирә, ир каршында, балалар янында үзеңне ничек тотарга кирәклекне сүз белән генә түгел, эш белән күрсәтә белде, – дип сөйли Насыйбуллиннарның кызлары Фирдания Зарифуллина.

Сания апа аш-суга да оста. Авылда аның теленңне йотарлык камыр ризыкларын авыз итмәгән кеше юктыр. Ризван абый – мәзәкчән, тәгәл, чиста, тырыш кеше. Яшь чакларында болында печән чапканда, аның артыннан куып җитә алмаганнар.

–Эшебез уртак булды. Балаларны да хезмәт яратырга өйрәттек, – ди Насыйбуллиннар, тату яшәү сере турында сорагач.

Бүген аларның 17 оныклары, дүрт оныкчыклары бар. Хәер, күрше-күләннең балалары да аларны әби белән бабай дип йөртә. Әле озак еллар шулай башкаларга үрнәк булып, татулыкта, тигезлектә яшәргә язсын иде бу гаиләгә.

Эльвира МОЗАФФАР.

**Туй дигәч тә, элек авыл урамнарыннан гармуннарын сыздырып, җырлашып кунактан-кунакка йөргәннәре искә төшә. Икешәр-өчәр көн туй итәләр иде ул чакларда. Табын түрендә – күрше-күлән бергә җыелышып әзерләгән ризыклар. Туйга бүләк итеп урын-җир, сөлге ише әйберләр салынуы гадәти күренеш буларак кабул ителгән. Алып баручы итеп табындагылар арасыннан бер җор теллесе сайлап алынган.**

# Туйда туган уйлар

Балаларының язмышын да ата-ана үзе хәл иткән. Бүген бик азы гына әти-әнисе таныштырган кеше белән гаилә кора. Аларга ата-ана белән торасы түгел, янәсе.

Хәзерге туйларга әзерлек иң элек тамада эзләүдән башлана. Хәленнән килгәннәре сиксәнешәр меңлеген чакырса, акча жәлләгәннәре иң аз дигәне белән канәгатьләнә. Кунакларны берничә сәгать күңел ачтыру өчен шулкадәр акча сорап алуны үзем берничек тә аңламыйм. Аз дигәннәре дә утызар мең тора бит аның. Нишлисең, бирүчесе булгач, алучысы табыла инде. Әнә шул азрак акча алганы шәбрәк тә алып бара әле. Туй башлангач, кунаклар белән таныштыру, теләкләр теләү бер сәгатькә сузыла. Тартма тотып яшь парларга бүләк итеп акча җыйганнан соң, тамада берничә җыр башкара. Аңа туйны алып бару өчен вакыты да санаулы гына кала. Кайбер тамадалар туйның башыннан ахырына кадәр, төрле юллар белән, акча җыю ягын карыйлар. Туачак балалар өчен бәләкәй колготкиларга җыйнау дисеңме, кияү белән кәләш фотосы төшерелгән этикетка белән шампан шәрабен сатып алуы... 200 сум чамасы торган шампан шәрабен өч-дүрт меңгә сатып алучыга табындагыларның күбесе гаҗәпләнеп карый. Кемдер «бигрәк бай кеше» дип, кемдер «саф акыллы кешеме икән бу», дип уйлый андыйлар турында. Шул бай дигәнеңнең үз гомерендә берәр шәфкатьлелек акциясендә катнашканы бармы икән, дип уйлап куясың. Кеше алдында күрсәтү өчен кылынган ул гамәл «менә без ничек яшибез» дигәнне аңлата.

Элек мәҗлеснең бер башында – ирләр, икенче башында хатын-кызлар утырса, хәзер бер башта – өлкәнрәкләр, икенчесендә яшьләр урын ала. Туйлар ресторан, кафеларда узган мәҗлесләргә баерак туганнарын чакырырга тырышалар. Соңыннан күпме акча җыелганын, кемнең ничә сум салганын сөйләп йөрүчеләре дә булмый калмый, әлбәттә. Табыннарын әзерләгәндә, андагы ризыкны бөтен кеше дә ашый алырлыкмы икәнен уйлап та карамый кайберәүләр. Диетик ризыклар гына ашап ияләшкән кеше туйдан ач килеш кайтып китәргә мөмкин. Ә аларны рәттән ашасаң, ашказаны яисә бавыр өянәге кузгалуын көт тә тор. «Туйга барсаң, туеп бар», – дип шундыйларга карата әйтелгәндер дә инде. Һәр заманның үз көе дигәндәй, туйлар да үзгәрә шул...

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

# Зөләйха күзләрен ача

→ Дәвамы.

Менә инде тәкәләрнең колак тондыргыч бәэлдәүләре, бер-берен этәртөртә, салпы колакларын селкетеп һәм кара нечкә аяклары белән тибенә-тибенә, бер-берсенә сикерешеп менүләр башланды. Денисов, учларын тырпайтып, барысын да «абзарга» – бер урынны икегә бүлеп торган озын тукыма пәрдә артына куып кертте. Соңгы булып калган елгыр бәрән, агач идәнгә тояклары белән вак-вак типкәләп, һаман йөгереп йөри. Рәис аны, ниһаять, бөдрәле сыртыннан эләктереп алды да башкалар янына кертеп җибәрде. Канәгать калып, тирә-юньгә карап алды, итеге белән тәкәләрнең исле, укмашкан йоннарына тибеп куйды, кулларын кунакчыллык белән җәеп җибәрде. Изүеннән тельняшканың буй-буй сызыклары күренеп тора.

– Ә мин нәрсә дидем?!

Игнатов, башын күтәреп, күз йөртеп чыкты. Керосин лампасының ачык яктысы биек агач түшәмне яктыртып тора. Тар, озын тәрәзәләр түгәрәк гөмбәз буйлап тезелешкән. Караңгы, сумала булып каткан диварларда – яртылаш кырылган гарәп язмаларының вак дулкыннары. Әле күптән түгел генә эленгән җирләреннән алынган ләүхәләрнең (язма догаларның) эзләре, сизелер-сизелмәс якты квадратлар булып җемелдәп торган уемнар мәгарә кебек акаеп тора.

Башта Игнатовның элекке мәчеттә төн чыгасы килмәде – бу карагруһчылар оясында нием калган? Ә хәзер менә уйланып утыра; дөрестән дә, ни игә калмаска?! Денисовның башы эшли, афәрин! Ни өчен әле шундый бина буш торырга тиеш?

– Урыннар барыгызга да җитә, – дип мактанды рәис, чәчәкле чаршауны тартып куйды. – Тәкәләр – хатын-кызлар ягында, кешеләр – ирләр ягында. Искелек калдыгы, билгеле, әмма җайлы, факт! Әүвәл чаршауны алырга уйлаган идек тә, аннары калдырасы иттек. Бездә бит кич җиттеме – кунак.

Мәчетне колхозга күптән түгел генә бирделәр. Хәтта сарык-тәкәләрнең сасы исе аның аерылып торган, әлегә кадәр һәр почмакта сакланып калган үзенчәлекле исен – әллә иске келәмнәр, әллә тузан баскан китаплардан калган исен күмеп китә алмый.




Керү ишеге янында туңып беткән күчеп баручылар өелеште, чаршауга курка-курка карап алалар, бит аның артындагы сарык-тәкәләр әлегә кадәр төртешә, акырыша.

– Урнашыгыз, сөрелгән гражданнар. – Денисов мич капкачын ачты да берничә утын пүләне өстәде. – Мин дә колхозчылар да башта ирләр ягына керергә курка иде, – диде шыпырт кына Игнатовка. Аннары иялəнделәр. Каракүл баш киеме кигән мулла мәчеткә беренче булып керде. Михрабның биек итеп ясалган уемына барып тезләнде. Аның артыннан берничә ир үтте. Хатын-кызлар элеккечә бусага төбендә җыелышып калды.

– Гражданочки! – дип, күтәренке күңел белән кычкырып җибәрде рәис, мич янында баскан килеш. Утның алтын ялкыннары аның кара күзләрендә ялтырап күренә. – Тәкәләр бит курыкмый, алардан үрнәк алыгыз.

Чаршау артыннан килгән колак яргыч бәэлдәүләр җавап булып яңгырады.

Мулла тезләнгән урыныннан торды. Күчеп баручыларга таба борылып, үзенә чакыргандай кулларын болгады. Кешеләр кыюсыз гына керделәр, стеналар буена сибелделәр.

Прокопенко, почмакта өелеп торган чүп-чар янына килеп чүгәләде, шушы чүп өеменнән бер китап казып чыгарды; аның металл белән бизәкләнгән матур тукыма тышлыгын тырнаклары белән казый башлады – аңбелемгә сусаган.

– Китапларга кагылмаска! – дип кисәтте рәис. – Мичкә ягу өчен бигрәкләр дә җайлы алар.

Гүзәл ЯХИНА

Флёра ТАРХАНОВА
тәрҗемәсе

– Бернәрсәне дә алмабыз, бернигә дә тимәбез, – диде Игнатов, ачулы күзләре белән Прокопенкога карап. Тегесе китапны әлеге чүп өеменә кире ташлады да җилкәсен ваемсыз гына җыерып куйды: артык исем китмәде, янәсе.

– Тыңла әле, вәкил, – Денисов Игнатовка борылды, – синең солдатларың кичке ашка тәкәне алып китмәсме? Миңа күчеп китүчеләр кәрваны туктаган саен, иртән ни дә булса юкка чыккан була. Гыйнвар аенда кötүнең яртысы – тю! Факт.

– Колхоз малын! Ничек инде шулай була ала?

– Ярар инде, ярар… – Денисов елмаеп куйды һәм Игнатовка кап-кара сөялләр каплаган нык, буынтыклы бармаклары белән шаярып янап алды: – Кайчакларда барысы артыннан да карап бетереп булмый бит.

Игнатов, тынычландырырга тырышып, Денисовның кулбашыннан какты: читләшмә, иптәш! Уйламассың да: Петербурның элекке моряги (Балтыйк буендагы) һәм Ленинград эшчесе (ударник! хәзер менә егермебишмеңче (романтик!) партия чакыруы белән совет авылын күтәрешергә килгән, кыскасы, барлык статьялар буенча да безнең кеше – үзеңнекеләр турында начар уйлау…

Настасья ялкауланып кына мәчет буйлап атлый, почмак саен кысылышкан күчеп китүчеләрне күзли. Башыннан йонлач папахасын салды да, бодай төсендәге сары авыр толымы аркасы буйлап аякларына кадәр шуып төште. Хатын-кызлар, моны күргәч, аһ иттеләр (мәчеттә ирләр янында, бигрәк тә мулла үзе утырганда, ябылмаган баш белән йөрү акылга сыймый!), учлары белән балаларның күзләрен капладылар. Настасья кызган мич янына килеп басты һәм толыбын мичкә япты. Гимнастёркасындагы бөрмәләр, тыгыз кыллар булып, күтәртмә күкрәкләренең киң каешы астына кадәр кереп киткән. Билендәге бу каеш шулкадәр нык кысылган, менә-менә зеңгелдәп шартлар төсле тоела.

– Монда балаларны яткырырбыз, – диде Игнатов, аңа карамыйча гына. «Тагын җәллимме?» – дип уйлап куйды, җеңләнеп. Шундук үзен тынычландырды: кулакныкылар булса да, балалар ич.

– Әй, туңармын бит, – дип шукланып әйтеп куйды Настасья һәм тунын мич өстеннән тартып алды.

– Әйдәле, мин сиңа печән ятагы ясыйм, Чибәркәй, – дип, күзен кысты Денисов.

Бала-чага, ыгы-зыгы килеп, басынкырак тавыш белән кычкырыша-кычкырыша, киң мич өстенә үрмәләде: кем өскәрәк, кем янәшә урнашты. Әниләре идәнгә киң тыгыз бөҗра булып яттылар. Калганнар үзләренә урынны стеналар буеннан эзләде – почмакта аунап яткан иске-москы, китап киштәләре һәм шкаф ватык-сыныклары өстенә урнашты.

Зөләйха яртылаш янган келәм кисәген табып алды да, аркасы белән стенага терәлеп, шуның өстенә ятты. Баштагы уйлар хәзергә кадәр авыр, ипи камыры кебек басынкы. Күзләр күрсә дә, ниндидер пәрдә аша гына караган кебек. Колаклар да ишетә, әмма һәр аваз ерактан килгән тавыш булып кына керә. Гәүдә хәрәкәттә, сулый, тик үзеңнеке түгел төсле.

→ Дәвамы бар.

**Башы 2015 елның декабрь, 2016 елның гыйнвар, февраль, март, апрель, май саннарында.**



**Ислам динендә бер генә нәрсә дә очраклы түгел. Дини гыйбадәтләрне генә алыйк, аларда рухи һәм физик сәламәтлек бергә үрелеп бара. Аның максаты да – адәм баласының җанын-тәнен таза-сау тоту, аны авырулардан саклау. Намаз укып, кеше күңел тынычлыгы таба, шул ук вакытта, намаздагы хәрәкәтләр ярдәмендә, сәламәтлеген дә яхшырта. Көнчыгыш илләрендә төрле медитацияләр, йога, цигун популяр, ислам динендә исә тән һәм күңел саулыгына намаз укып ирешеп була дигән фикердә тора Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе баш табибының оештыру-методик эш буенча урынбасары Рөстәм ФӘХЕРТДИНОВ.**



# «Намаз укып, сәламәтлегегезне яхшыртыгыз»

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА**

– Хәтта ки намазга кадәр алынган тәһарәтнең дә файдасы зур. Бердән, кеше чистарына. Икенчедән, аны үзенә күрә бер массаж дип тә әйтергә була. Икенче һөнәрем буенча мин невролог, әнә рефлексы терапиясе белән шөгыльләндем. Шуннан чыгып әйтә алам: тәһарәт алына торган урыннарда биологик актив нокталар урнашкан. Тәһарәт алган вакытта без су ярдәмендә аларны эшкә җигәбез. Кулларны юу төрле инфекцияләрдән саклый, бигрәк тә эчәклек инфекциясе таралуга юл куймый. Грипп эпидемиясе чорында табиблар борынны гел чайкап торырга куша. Бу да вируслы инфекцияләргә каршы профилактика булып тора. Тамакны чайкап, авыз куышлыгында җыелган бактерия һәм микроблардан арынабыз. Намазның үзенә килгәндә, әлеге гыйбадәт умыртка баганасы өчен файдалы. Буыннар хәрәкәт ярата. Көнелә биш тапкыр намаз укыган кеше физик күнегүләр дә ясый булып чыга. Димәк, ул – остеоартрозны булдырмау чарасы да. Намазын даими укыган кешенең кан әйләнеше әйбәтләнә, шул рәвешле, йөрәк мускулындагы канның әйләнеп йөрүе дә яхшыра. Шунысын да әйтергә кирәк: намаз вакытлары кеше организмындагы кан әйләнеше яңарган сәгатьләргә туры килә. Сәҗдәгә китүнең дә үзенә бер хикмәте бар. Башны аска игәндә, баш миенә кан килү яхшыра. Баш мие күзәнәкләре тукланып торгач, намаз укучыларда склероз бик сирәк күзәтелә. Рөкуг һәм сәҗдәгә киткәндә, кан тамырлары кысыла һәм киңәя, бу да алар өчен бер күнегү булып тора. Күпләр депрессиядән, күңел төшенкелегеннән, төрле нерв системасы авыруларыннан җәфаланa. Күңелне тынычландыра торган иң яхшы дәва ул – намаз. Әмма намазны физик сәламәтлек өчен генә укырга кирәкми. Намаз уку тән күнегүләренә генә әйләнеп калмасын, Аллаһны зикер итәргә, күңелең, телең һәм бөтен тәнең белән Раббыңны искә алырга тиешсең.

**– Намаздан соң тәсбих тарту бармаклар өчен файдалы икән...**

– Тәсбих тартканда, бармак очларында урнашкан биологик актив нокталарга басып, аларга һәм шуның белән бәйле рәвештә бөтен организмга массаж ясыйбыз булып чыга. Ул вак буыннарны сыгылмалы итә, сеңерләрне ныгыта. Артриттан җәфаланганнар өчен тәсбих тарту физик күнегү дә булып тора. Аның кан басымын көйләве дә билгеле.

**– Рөстәм Хәмитович, сәламәтлек турында сөйләгәндә, ураза турында әйтми калу мөмкин түгел.**

– Ураза җитәр алдыннан күпләр, минем ашказаным авырта, ач торырга ярыймы, дип сорыйлар. Ашказаны, уникеилле эчәк җәрәхәте (язва) вакытында ураза тотарга киңәш ителми. Ә менә гап-гади гастрит булганда мөмкин, кирәк тә дип әйтер идем мин, медицинада гастритны нәкъ менә ач тору ярдәмендә дәвалыйлар. Бигрәк тә ашказаны инфекциясе булганда. Ризык ашалмагач, ашказаны согы бүленеп чыкмый һәм шуның нәтиҗәсендә, ашказаны тизрәк дәвалана. Кеше күп ашап та авыруга сабыша. Шәригать буенча, без өстәл янынннан тамагыбыз туймыйча торып китәргә тиешбез. Пәйгамбәребез (с.г.с.) дә шулай эшләгән. «Адәм баласы тутыра торган капчыклар арасында корсактан да начар капчык юк. Кеше карынын өчкә бүлсен: бер өлешенә – аш, икенче өлешенә – су, өченче өлешенә һава тутырсын», – ди. Аның шулай ук: «Ураза тотыгыз, сәламәт булырсыз!» – дигән сүзләре дә билгеле. Димәк, ашказанын гына түгел, башка бик күп кенә чирләрне дә ач тору юлы белән дәвалыйлар. Тик шуны онытмагыз: уразаның асыл мәгънәсе – нәфесне чикләү, күңелне сафландыру, сабырлык тәрбияләү.

**– Мөселман хатын-кызларының хиҗаптан йөрүләрен дә шул ук сәламәтлек билгесе буларак та каргарга мөмкин?**

– Башка яулык бәйләп йөрү баш авыруларыннан, суык тиюдән, чәч коелудан саклый. Эссе көндә дә табиблар башка киеп йөрергә куша. Ул эссе сугудан саклый. Тәннең бөтен өлешен каплаган киемнәр исә тәнне кояш нурларыннан яшерә. Иң мөһиме: хиҗап күз тиюдән, начар энергетикадан саклый.

**– Сөннәткә утырту турында да искә алып китәргә кирәктер...**

– Сөннәткә утырту ир-атларга гигиеник максатта үткәрелә. Медицина белгечләре үткәргән тикшеренүләр сөннәтләүнең гигиена саклауда мөһим роль уйнавын дәлилли. Ул сидек юлында ялкынсыну барлыкка килү ихтималын киметә, венерик авырулардан саклый, җенси әгъзаларда рак авыруы барлыкка килүне кисәтә.

Гомумән, ислам дине ул – күңел һәм тән сәламәтлеге, дөрес яшәү рәвеше. Аллаһы Тәгалә кушканнарны төгәл үтәп яшәсәк, рухыбыз да, тәнебез дә сау булыр.

# Бәраәт кичәсе якынлаша

**Быел Бәраәт кичәсе 21 майдан 22сенә каршы төнгә туры килә. Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт» бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган вакыт. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә. Бу кичәдә Хак Тәгалә бәндәләренә гөнаһлардан арыну, рухи пакьләнү мөмкинлеге бирә.**

Ислам галимнәре билгеләвенчә, Кадер кичәсеннән соң иң изге кичә — Бәраәт кичәседер. Чөнки Коръән беренче мәртәбә Бәраәт кичәсендә дөнья күгенә иңдерелгән һәм Кадер кичәсендә Пәйгамбәребезгә төшерелә башлаган.

Бу кичәдә Пәйгамбәребез (с.г.с.) агасы хәзрәте Габбас разыйаллаһу гәнһене тәсбих намазын укырга өндәгән. Бәраәт кичәсенең үз намазы да бар. Бу намазда «Әлхәм» сүрәсеннән соң «Аятел-Көрси» белән «Иннә-әнзәлләһ» сүрәләрен уку күркәм гадәт булыр.

Бу кичәдә өч мәртәбә «Йәсин» сүрәсе укылыр. Беренче мәртәбә «Йәсин» сүрәсен укыганда укучының нияте Аллаһы Тәгаләдән озын гомер сораудан гыйбарәт булыр, икенче мәртәбә «Йәсин» укыганда мөселман Аллаһы Тәгаләдән бәла-казалардан иминлек сорар. Өченче мәртәбә бәрәкәт артсын дип укыр.

**(«Татар мөселман календаре»)**



## 16 МАЙ – ДҮШӘМБЕ

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
05:10 «Җомга киче». Концерт (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Одна ночь любви». Телесериал (12+)
10:00 «Сыргалым». Телесериал (12+)
11:00 «Оныта алмыйм...». Ретро-концерт (0+)
11:30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
12:00 «Отряд». Телесериал (16+)
13:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14:00 Новости Татарстана (12+)
14:15 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
14:55 «Тиззарядка» (0+)
15:00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Тамчы шоу» (0+)
15:55 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:10 «ТИН-клуб» (6+)
16:30 «Приключения Папируса». Мультсериал (0+)
17:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17:30 «Сыргалым». Телесериал (12+)
18:30 Новости Татарстана (12+)
19:00 «Прямая связь» (12+)
20:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
20:30 «Татарлар» (12+)
21:00 «Күчтәнәч» (0+)

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
07:45 «Нәсыйхәт» (6+)
08:15 «Тамчы-шоу» (0+)
08:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Караоке бәйге» (6+)
11:10 «Татарлар» (6+)
11:30 «Халкым минем...» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Әдәби хәзинә» (6+)
12:45 «Сыргалым». Телесериал (12+)
13:30 «Уеннан уймак-2». Телевизион нәфис фильм. Беренче серия (12+)
14:20 «Мең дә бер җавап» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Тиззарядка» (0+)
15:20 «Күчтәнәч» (0+)
15:35 «Тамчы-шоу» (0+)
16:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
17:30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Сыргалым». Телесериал (12+)
19:10 «Халкым минем...» (12+)
19:40 «Әдәби хәзинә» (6+)
20:05 «Татарлар» (6+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)

### «РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.35 «Парламентские вести»
14.30 «Яңалыклар. Татарстан»
17.30, 19.35 «Вести – Татарстан»

### ПЕРВЫЙ
5.00 Телеканал «Доброе утро»
9.00, 3.00 Новости
9.20, 4.05 Контрольная закупка
9.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55, 3.05 Модный приговор
12.00, 15.00 Новости с субтитрами
12.15 «Пусть говорят» (16+)
13.25 «Таблетка» (16+)
13.55, 15.15, 1.15 «Время покажет» (16+)
16.00 «Мужское / Женское» (16+)
17.00, 2.05 «Наедине со всеми» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.45 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым (16+)
21.00 Время

### РОССИЯ 1
5.00, 9.15 Утро России
9.00, 11.00, 14.00, 17.00, 17.50, 20.00 Вести
9.55 «О самом главном»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 Местное время. Вести-Москва
11.55 Т/с «Тайны следствия» (12+)
14.50 Вести. Дежурная часть
15.00 Т/с «Верни мою любовь» (12+)
18.15 «Прямой эфир» (16+)
21.00 Т/с «Миндальный привкус любви» (12+)
23.50 Честный детектив (16+)
0.50 Д/ф «Дуэль разведок. Россия-США». «Иные. Мозг всемогущий» (12+)
2.25 Т/с «Срочно в номер. На службе закона» (12+)
3.25 Д/ф «ТАСС. Со скоростью молнии» (12+)
4.20 Комната смеха

### НТВ
5.00 Т/с «Супруги» (16+)
6.00 «Новое утро»
9.00 Т/с «Возвращение Мухтара» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 Т/с «Москва. Три вокзала» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.20 Обзор. Чрезвычайное происшествие
13.50 «Место встречи»
15.00 Т/с «Отдел 44» (16+)
16.20 Т/с «Улицы разбитых фонарей» (16+)
18.00 «Говорим и показываем» с Леонидом Закошанским (16+)
19.40 Т/с «Пёс» (16+)
22.30 «Итоги дня»
22.55 Т/с «Морские дьяволы. Смерч» (16+)
0.50 «Место встречи» (16+)
2.00 Т/с «Законы улиц» (16+)
4.00 Т/с «ППС» (16+)

### КУЛЬТУРА
7.00 Евроньюс
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры
10.15, 1.40 «Наблюдатель»
11.15 Х/ф «Мужество»
12.25 «Линия жизни»
13.20 Х/ф «Белый орел»
14.40 Д/ф «Берлинский остров музеев. Прусская сокровищница»
15.10 «Михаил Булгаков. Черный снег»
15.40 Х/ф «Театральный роман»
17.30 Неделя фортепианной музыки
18.50 Третьяковка-дар бесценный!
19.15 «Спокойной ночи, малыши!»
19.45 «Главная роль»
20.05 «Сати. Нескучная классика...»
20.45 «Правила жизни»
21.20 Д/ф «Хранят так много дорогого, или Эрдман и Степанова: двойной портрет в интерьере эпохи»
22.15 «Тем временем» с Александром Архангельским
23.00 Д/с «Запечатленное время»
23.45 Худсовет

### РЕН ТВ
5.00, 4.45 «Территория заблуждений» с Игорем Прокопенко (16+)
6.00, 11.00 «Документальный проект» (16+)
7.00 «С бодрым утром!» (16+)
8.30, 12.30, 16.30, 19.30, 23.00 «Новости» (16+)
9.00 «Военная тайна» с Игорем Прокопенко (16+)
12.00, 16.00, 19.00 «Информационная программа 112» (16+)
13.00 Званый ужин (16+)
14.00 Х/ф «Танго и Кэш» (16+)
17.00, 4.00 «Тайны Чапман» (16+)
18.00, 1.30 «Самые шокирующие гипотезы» (16+)
20.00 Х/ф «Викинги против пришельцев» (16+)
22.10 «Водить по-русски» (16+)

### СТС
6.00 М/с «Приключения Джеки Чана» (6+)
6.25 М/с «Команда «Мстители» (12+)
7.00 «Взвешенные люди» (16+)
9.00 «Ералаш» (0+)
9.30 Шоу «Уральских пельменей» (16+)
11.00 Х/ф «Человек-паук-2» (12+)
13.30, 23.40 «Уральские пельмени» (16+)
14.15 Х/ф «Человек-паук-3: Враг в отражении» (12+)
17.00 Т/с «Кухня» (16+)
20.00 Т/с Премьера! «Беглые родственники» (16+)
21.00 Т/с «Пушкин» (16+)
22.00 Х/ф «Супернянь» (16+)

### МАТЧ ТВ
6.30 Д/с «Дублер» (16+)
7.00, 9.00, 11.20, 15.00 Новости
7.05, 12.00, 0.45 Все на Матч!
9.05 Хоккей. Дания-Чехия. Чемпионат мира. Трансляция из Москвы
11.25 Д/ф «Звезды шахматного королевства» (12+)
12.45 Хоккей. Словакия-Финляндия. Чемпионат мира. Трансляция из Санкт-Петербурга
15.10, 18.45 Все на хоккей!
16.10 Хоккей. Россия-Норвегия. Чемпионат мира. Прямая трансляция из Москвы
19.15 Росгосстрах. ЦСКА-«Краснодар». Чемпионат России по футболу. Прямая трансляция
21.30 «После футбола с Георгием Черданцевым»

## 17 МАЙ – СИШӘМБЕ

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
05:10 «Мәдәният дөньясында» (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Одна ночь любви». Телесериал (12+)
10:00 «Сыргалым». Телесериал (12+)
11:00 «Оныта алмыйм...». Ретро-концерт (0+)
11:30 «Туган җир» (12+)
12:00 «Отряд». Телесериал (16+)
13:00 «Секреты татарской кухни» (12+)
13:30 «Размышления о вере. Путь к исламу» (6+)
13:35 «Путь» (12+)
14:00 Новости Татарстана (12+)
14:15 «Музыкаль каймак» (12+)
14:55 «Тиззарядка» (0+)
15:00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
15:55 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:10 «Мастера» (6+)
16:35 «Һөнәр» (6+)
17:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17:30 «Сыргалым». Телесериал (12+)
18:30 Новости Татарстана (12+)
19:00 «Национальный вопрос. Телемост Москва-Казань» (12+)
20:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
20:30 «Татарлар» (12+)
21:00 «Күчтәнәч» (0+)

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
07:45 «Канун. Парлемент. Җәмгыять» (12+)
08:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
08:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Башваткыч» (6+)
11:10 «Татарлар» (6+)
11:30 «Туган җир» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Әдәби хәзинә» (6+)
12:45 «Сыргалым». Телесериал (12+)
13:30 «Уеннан уймак-2». Телевизион нәфис фильм. Икенче серия (12+)
14:20 «Мең дә бер җавап» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Тиззарядка» (0+)
15:20 «Күчтәнәч» (0+)
15:35 «Яшьләр тукталышы» (12+)
16:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
17:30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Сыргалым». Телесериал (12+)
19:10 «Туган җир» (12+)
19:40 «Кичке аш» (6+)
20:05 «Татарлар» (6+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)

### «РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Современник». Георгий Виноградов
9.30 «Психология и мы»
9.45 «Киноафиша»
11.35 «Вести – Татарстан»
14.30 «Яңалыклар. Татарстан»
17.30, 19.35 «Вести – Татарстан»

### ПЕРВЫЙ
5.00 Телеканал «Доброе утро»
9.00, 3.00 Новости
9.20, 4.05 Контрольная закупка
9.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55, 3.05 Модный приговор
12.00, 15.00 Новости с субтитрами
12.15 «Пусть говорят» (16+)
13.25 «Таблетка» (16+)
13.55, 15.15, 2.15 «Время покажет» (16+)
16.00 «Мужское / Женское» (16+)
17.00, 1.20 «Наедине со всеми» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.40 «Давай поженимся!» (16+)
19.45 Время
20.15 Чемпионат мира по хоккею-2016. Сборная России-сборная Швеции. Прямой эфир
22.25 Т/с Премьера. «Ищейка» (12+)

### РОССИЯ 1
5.00, 9.15 Утро России
9.00, 11.00, 14.00, 17.00, 17.50, 20.00 Вести
9.55 «О самом главном»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 Местное время. Вести-Москва
11.55 Т/с «Тайны следствия» (12+)
14.50 Вести. Дежурная часть
15.00 Т/с «Верни мою любовь» (12+)
18.15 «Прямой эфир» (16+)
21.00 Т/с «Миндальный привкус любви» (12+)

### НТВ
5.00 Т/с «Супруги» (16+)
6.00 «Новое утро»
9.00 Т/с «Возвращение Мухтара» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 Т/с «Москва. Три вокзала» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.20 Обзор. Чрезвычайное происшествие
13.50 «Место встречи»
15.00 Т/с «Отдел 44» (16+)
16.20 Т/с «Улицы разбитых фонарей» (16+)
18.00 «Говорим и показываем» с Леонидом Закошанским (16+)
19.40 Т/с «Пёс» (16+)
22.30 «Итоги дня»

### КУЛЬТУРА
6.30 Евроньюс
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры
10.15, 1.55 «Наблюдатель»
11.15 Т/с «Коломбо»
12.25 Д/с «Запечатленное время»
12.55 «Пятое измерение»
13.20 Х/ф «Праздник Святого Иоргена»
15.10 «Михаил Булгаков. Черный снег»
15.40 «Сати. Нескучная классика...»
16.25 Д/ф «Хранят так много дорогого, или Эрдман и Степанова: двойной портрет в интерьере эпохи»
17.20 Д/ф «Властелины кольца. История создания синхрофазотрона»
17.50 Неделя фортепианной музыки
18.25 Д/ф «Библос. От рыбацкой деревни до города»
18.50 Третьяковка-дар бесценный!
19.15 «Спокойной ночи, малыши!»
19.45 «Главная роль»
20.05 Искусственный отбор
20.45 «Правила жизни»
21.10 Закрытие XV Московского Пасхального фестиваля. Трансляция из КЗЧ

### РЕН ТВ
5.00, 4.45 «Территория заблуждений» с Игорем Прокопенко (16+)
6.00, 11.00 «Документальный проект» (16+)
7.00 «С бодрым утром!» (16+)
8.30, 12.30, 16.30, 19.30, 23.00 «Новости» (16+)
9.00 «Военная тайна» с Игорем Прокопенко (16+)
12.00, 16.05, 19.00 «Информационная программа 112» (16+)
13.00 Званый ужин (16+)
14.00 Х/ф «Викинги против пришельцев» (16+)
17.00, 4.00 «Тайны Чапман» (16+)
18.00, 1.30 «Самые шокирующие гипотезы» (16+)
20.00 Х/ф «Красная планета» (16+)
22.00 «Водить по-русски» (16+)

### СТС
6.00 М/с «Приключения Джеки Чана» (6+)
6.25 М/с «Команда «Мстители» (12+)
6.55 М/с «Колобанга. Только для пользователей интернета!» (0+)
7.10 М/с «Драконы и всадники Олуха» (6+)
9.00 «Ералаш» (0+)
9.50 Х/ф «Супернянь» (16+)
11.30 Т/с «Последний из Магикян» (12+)
14.00 Т/с «Воронины» (16+)
16.00 Т/с «Кухня» (16+)
20.00 Т/с Премьера! «Беглые родственники» (16+)
21.00 Т/с Премьера! «Пушкин» (16+)

### МАТЧ ТВ
6.30 Д/с «Дублер» (16+)
7.00, 9.00, 11.20 Новости
7.05, 23.00 Все на Матч!
9.05 Хоккей. Канада-Франция. Чемпионат мира. Трансляция из Санкт-Петербурга
11.25 Специальный репортаж (16+)
11.40, 14.45, 15.40, 18.45, 19.45, 22.45 Все на хоккей!
12.10 Хоккей. Чехия-Швейцария. Чемпионат мира. Прямая трансляция из Москвы
15.15 Д/ф «Холоднее льда. Сборная Латвии» (12+)
16.10 Хоккей. Латвия-Норвегия. Чемпионат мира. Прямая трансляция из Москвы
19.15 «Рио ждет» (16+)
20.10 Хоккей. Канада-Финляндия. Чемпионат мира. Прямая трансляция из Санкт-Петербурга
23.45 Хоккей. США -Словакия. Чемпионат мира. Трансляция из Санкт-Петербурга
2.00 Хоккей. Белоруссия-Франция. Чемпионат мира. Трансляция из Санкт-Петербурга
4.15 Чемпионат Европы по водным видам спорта. Трансляция из Великобритании
6.00 Д/с «Первые леди» (16+)

## 18 МАЙ – ЧӘРШӘМБЕ

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
05:10 «Караоке бәйге» (6+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Одна ночь любви». Телесериал (12+)
10:00 «Сыргалым». Телесериал (12+)
10:55 «Дин вә хәят» (6+)
11:00 «Оныта алмыйм...». Ретро-концерт (0+)
11:30 «Халкым минем...» (12+)
12:00 «Отряд». Телесериал (16+)
13:00 «Среда обитания» (12+)
13:30 Документальный фильм (12+)
14:00 Новости Татарстана (12+)
14:20 «Каравай» (6+)
14:55 «Тиззарядка» (0+)
15:00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Без – Тукай оныклары» (0+)
15:45 «Һөнәр» (6+)
16:00 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:15 «Приключения Папируса». Мультсериал (0+)
17:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17:30 «Сыргалым». Телесериал (12+)
18:30 Новости Татарстана (12+)
19:00 «Народный контроль» (12+)
19:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
20:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
20:30 «Татарлар» (12+)
21:00 «Күчтәнәч» (0+)
21:15 «Хочу мультфильм!» (0+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вечерняя игра» с Владимиром Яковлевым» (12+)
23:00 «Видеоспорт» (12+)
23:30 «Отряд»». Телесериал (16+)
00:20 «Одна ночь любви». Телесериал (12+)
01:15 «Сыргалым». Телесериал (12+)
02:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
03:40 «Халкым минем...» (12+)
04:05 «Яшьләр тукталышы» (12+)
04:30 «Оныта алмыйм...». Ретро-концерт (0+)

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
07:45 «Халкым минем...» (12+)
08:15 «Поем и учим татарский язык» (0+)
08:30 «Һөнәр» (6+)
08:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Яшьләр on-line» (12+)
11:10 «Татарлар» (6+)
11:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Регион» (6+)
12:45 «Сыргалым-2». Телесериал (12+)
13:30 «Уеннан уймак-2». Телевизион нәфис фильм. Өченче серия (12+)
14:05 «Татар халык җырлары» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Тиззарядка» (0+)
15:20 «Күчтәнәч» (0+)
15:35 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:50 «Мең дә бер җавап» (0+)
16:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
17:30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Сыргалым-2». Телесериал (12+)
19:10 «Регион» (6+)
19:40 «Белем дөньясы» (6+)
20:05 «Татарлар» (6+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Уеннан уймак-2». Телевизион нәфис фильм. Өченче серия (12+)
23:20 «Татар халык җырлары» (0+)
23:55 «Дин вә хәят» (6+)
00:00 «Яңалыклар» (12+)
00:15 «Халкым минем...» (12+)
00:40 «Татарлар» (6+)
01:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
02:45 «Нәсыйхәт» (6+)
03:10 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
04:05 «Яшьләр on-line» (12+)
04:55 «Уеннан уймак-2». Телевизион нәфис фильм. Өченче серия (12+)
05:30 «Халкым минем...» (12+)

### РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.35 «Вести – Татарстан»
14.30 «Яңалыклар. Татарстан»
17.30, 19.35 «Вести – Татарстан»

### ПЕРВЫЙ
5.00 Телеканал «Доброе утро»
9.00, 3.00 Новости
9.20, 4.20 Контрольная закупка
9.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55, 3.20 Модный приговор
12.00, 15.00 Новости с субтитрами
12.15 «Пусть говорят» (16+)
13.25 «Таблетка» (16+)
13.55, 15.15, 2.30, 3.05 «Время покажет» (16+)
16.00 «Мужское / Женское» (16+)
17.00, 1.35 «Наедине со всеми» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.45 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым (16+)
21.00 Время
21.35 Т/с Премьера. «Ищейка» (12+)
23.40 «Вечерний Ургант» (16+)
0.15 Ночные новости
0.30 «Политика» (16+)

### РОССИЯ 1
5.00, 9.15 Утро России
9.00, 11.00, 14.00, 17.00, 17.50, 20.00 Вести
9.55 «О самом главном»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 Местное время. Вести-Москва
11.55 Т/с «Тайны следствия» (12+)
14.50 Вести. Дежурная часть
15.00 Т/с «Верни мою любовь» (12+)
18.15 «Прямой эфир» (16+)
21.00 Т/с «Миндальный привкус любви» (12+)
22.55 Специальный корреспондент (16+)
0.40 Д/ф «Код Кирилла. Рождение цивилизации». «Научные сенсации. Мой враг-мозг» (12+)
2.50 Т/с «Срочно в номер. На службе закона» (12+)
3.50 Комната смеха

### НТВ
5.00 Т/с «Супруги» (16+)
6.00 «Новое утро»
9.00 Т/с «Возвращение Мухтара» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 Т/с «Москва. Три вокзала» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.20 Обзор. Чрезвычайное происшествие
13.50 «Место встречи»
15.00 Т/с «Отдел 44» (16+)
16.20 Т/с «Улицы разбитых фонарей» (16+)
18.00 «Говорим и показываем» с Леонидом Закошанским (16+)
19.40 Т/с «Пёс» (16+)
22.30 «Итоги дня»
22.55 Т/с «Морские дьяволы. Смерч» (16+)
0.50 «Место встречи» (16+)
2.00 Т/с «Законы улиц» (16+)
2.55 Квартирный вопрос (0+)
4.00 Т/с «ППС» (16+)

### КУЛЬТУРА
6.30 Евроньюс
